# Вөждан бурычы

(Рәшит Башаров 1965 ел)

/Вакыйга безнең көннәрдә Татарстан авылларының берсендә бара/

Катнашалар:
**Зөлфия** – зоотехник, 25-26 яшьләрдә
**Фәрит** – аның ире, 28-29 яшьләрдә
**Равиль** – колхоз председателе, 35-38 яшьләрдә
**Илһам** – партоешма секретаре, 35-38 яшьләрдә
**Люция** – клуб мөдире, МТФ да агитатор, 21-22 яшьләрдә
**Нурия** – савымчы, 19-21 яшьләрдә
**Наиль** – терлекчелектә механизатор, 25-26 яшьләрдә
**Фәнис** – ферма мөдире, 27-28 яшьләрдә
**Фатыйма** – савымчы, 37-39 яшьләрдә
**Ясәви** – каравылчы, 60 яшьтә
**Гыйльми** – аның хатыны, 55-57 яшьләрдә
**Имай** – терлекче, 40-42 яшьләрдә
**Почтальон кыз**

## I пәрдә

I күренеш

/Җәйләү. Кич. Уң якта терлекчеләр өе күренә. Сул якта күл. Өй каршында 2-3 күчермә өстәл. Терлекчеләр зооукуда. Зөлфия плакатлар ярдәмендә сыерларны ашату рационы турында сөйли/

**Зөлфия**: Шулай итеп, иптәшләр,13-14 кг сөт алу өчен, һәр сыерга көнгә 18-19 азык берәмлеге кирәргә тиеш. Ә без ашата торган азыкларның туклыклылыгы түбәндәгечә: безнең шартларда көтүлектә һәр сыер 40-50 кг яшел үлән ашый, бу 8 азык берәмлеге дигән сүз. Өстәмә бирелә торган 5 кг силос – 1, 3 кг комбиазык – 3, 20-30 – арыш уҗымы – 5 азык берәмлеге була. Димәк, безнең һәр сыердан 13-14 кг сөт алырга мөмкинчелегебез бар.

**Нурия**: Ә безнең кайбер сыерларның сөте 9-10 кг нан артмый. Сәбәбе нәрсәдә соң аның, Зөлфия апа?

**Зөлфия:** Моның сәбәпләре бар, Нурия. Безнең фермада нәселсез сыерлар да, ашатуда кайбер җитешсезлекләр дә бар. Ул турыда киләсе занятиедә сөйләшербез. Барыбыз бергә бу кимчелекләрне бетерербез дип уйлыйм, иптәшләр. Ярый, иртәгә контроль саву, ял итегез! Тыныч йокы…
/савымчылар сөйләшә-сөйләшә таралалар. Зөлфия ялгыз/ Әйе, тырышлар, барысы булмаса да эшләрен яраталар. Ә мин? Мин дә яратам шул. Эшем хакына барысын да ташладым... Нишли икән минем кадерлем, күз нурым? Юксынадыр инде. Эх, бу тормыш дулкыны!/Уйланып/

Акрын гына Фәнис чыга, тыңлый.
**Фәнис:** /үзенә/ Бәхет йолдызы кабынды дип кенә уйлый идем, баксаң, аның сөйгәне бар ... Шулай да күңел кылларын тартып карыйм әле. Зөлфия, гафу итегез, уйларыгызны бүлдем ахры...

**Зөлфия:** Зара юк, Фәнис. Мин үзегезне күрә алмадым дип борчыла төшкән идем. Әле генә зооукуны тәмамладык. Я, киңәшмәдә ниләр хәл иттегез?

**Фәнис:** Анда, гадәттә, эш турында сөйләшәләр инде. Сүз алган йөкләмәләрнең үтәлеше турында барды. Безнең адреска да тәнкыйть сүзләре булды. Сөт буенча алдырып булмый бит, Зөлфия.

**Зөлфия**: Әйе, рацион көн дә 13-14 литр алырлык итеп төзелгән, көтүлек тә әйбәт, ә сөт аз. Нәсел яңарту турында бер дә уйланмаган шул. Фермада 8-9 литрдан арттырмаган сыерларның ничә процент икәнен беләсеңме? 18-19% тәшкил итәләр алар.

**Фәнис:** Зөлфия, әйдә бүгенгә бу темага сөйләшүне калдырыйк! Киче нинди матур! Ник соң без һәрвакыт эш турында гына сөйләшәбез? Кайчан гына булмасын, сөт-ит , ит-сөт... Без бит в конце концов кеше, робот түгел... Әйдә, Зөлфия, кичке һава сулап, күл кырыннан әйләнеп килик!

**Зөлфия:** Рәхмәт, Фәнис, минем хисләргә бирелерлек вакытым да юк, булса да, мин аларга ялгыз чумарга яратам. Хәзергә хушыгыз! Иртәгә контроль саву, йоклап калмагыз! /китә/

**Фәнис:** Бу нинди серле сандык булды? Эш тә эш. Аны мин дә яратам, җиң сызганып эшлим. Ләкин мин дә кеше бит. Күңел түрендәге хисләр уянгач, эш турында гына уйлатмый икән шул, Зөлфия. Тынычлыгымны боздың син...

/Җырлый/
Күңел түрендәге хисләремне
Белдерергә сиңа омтылам.
Аңламыйсың, ахры, Зөлфиякәй,
Мәхәббәтең утында янам.
　　Уяттың син тыныч күңелемне,
　　Тибрәттең бит күңел кылларын,
　　Аңламыйсың ахры, Зөлфиякәй,
　　Дәрт бирде кояштай нурларың...

/Таяк тотып Ясави керә, җырны тыңлый, утыра/

**Ясави:** Әтнәкә, улым Фәнис, матур җырлыйсың икән. Синең җырлау түгел, кеше белән сөйләшкәнеңне дә күргән юк иде. Нәрсә... Әтнәкә, яшьлек үзенекен

итә... Зөлфия дип җырлыйсыңмы әле, улым? Әллә зоотехник Зөлфиягә гыйшык тотасыңмы?
**Фәнис:** Юк, Ясәви бабай, бу җыр ошаганга гына җырлыйм...

**Ясәви:** Ярый, ярый, улым, ничек тә гаеп түгел. Зоотехник Зөлфия дә әйбәт. Кече күңелле кыз. Килгәч тә: "Бабай, таныш булыйк, мин сезгә зоотехник булып килдем, исемем Зөлфия, рөхсәт итсәгез сездә торачакмын", - дип каян килгәнен әйтте, бездә эшләр ничек барганын сорашты. Үзе яшь, ләкин акыллы күренә. Шулай булгач, яратырга да, яраттырырга да лаеклы кыз. Әтнәкә, улым, мин малкайларны барлап килим әле.  /Китә/

**Фәнис:** Әйе. Бабай хаклы, Зөлфия сөяргә дә. сөелергә дә лаек кыз. Тик нигәдер читләшә... Әллә үзенә тиң күрми инде – ул югары белемле галим-зоотехник, ә мин? Юк, минемчә бу төп сәбәп түгел, бередә башка сәбәп бар...
Ярый, иртәгә көн бар бит әле. Зөлфия әйтмешли, хисләреңне чәчмә, егет, эшне онытма! /Китә/

Имай керә, бераз кызмача.

**Имай:** Яратам шул айлы кичләрне. Әз генә кәеф тә булса, бигрәк рәхәт була... Бүген тагын тыныч. Бер капчык – бер литр, ә мине эчәсең диләр. Авызга үзе керә ич.

**Ясәви:** /керә/ Имай тагын кәефле. Исәнме, Имаметдин!

**Имай:** Исән-сау, эшләр гөрли, Ясәви ага.

**Ясәви:** Әтнәкә, Имаметдин, яратасың шайтан суын. Семьяң, балаларың турында уйлар идең!

**Имай:** Дуңгызда да була бит ул бала. Үсәрләр әле. Тапкан, 10-12 яшькә кадәр үстергән. Миннән тагын ни кирәк?

**Ясәви:** Әй, Имаметдин, Имаметдин... Наҗияңә күз төшер... Саргаеп, кибеп бетте. Ачлыктан түгел бит ул. Үзе эшли, үзе бала тәрбияли, алар өстенә сине көйли.

**Имай:** Эше шул. Мин берсенә дә мәҗбүр итмим аны. Торасы килмәсә, китсен.

**Ясәви:** Әтнәкә, Имаметдин, яшь чакта мондый түгел идең син, дөньяны ярата, Наҗияң өчен үләргә җитеп тора идең. Бүген тагын бередә кунасыңмы?

**Имай:** Бу рәхәтлекне ташлап, ник кайтыйм мин. Анда мине ни көтә – күз яшьләре, җыелып талау. Юк, миңа монда рәхәт. Сәхрә патшасы мин монда.

**Ясәви:** Әтнәкә, әйткәнне һич аңламыйсың икән син. Синең белән сүз кушырып торган мин җүләр. Малкайлар белән сөйләшсәм, күңелем тынычрак булыр./Китә/.

**Имай:** Киңәш бирә, имеш, акыл сата. Минем үз акылым үземә җитәрлек, картлач. /Аракы чыгара, стакан ала, сала/

Җырлый: Стаканның төпләрендә
Тәңкә сыйфатлары бар.
Эчеп җибәр әле, Имай,
Тәнгә сихәтләре бар. /Эчә/

Эх, шәп булды да соң. Ә миңа кайт диләр. Дөньяның бу рәхәтлеген сатып та алып булмый бит. Кешеләр отпускасын табигать кочагында үткәрәм дип, шәһәр тикле шәһәрдән киләләр. Ә безгә бесплатный бит бу рәхәтлек, прәме җәннәт.

Семья, имеш, хатын, балалар... Аларга ни кирәк. Йорт яхшы, икмәк, ит, бәрәңге җитәрлек, сөт чишмәсе абзарда. Әй, чукынып китсен, миңа бүгенгесе рәхәт. Эчә, имеш, бесплатный килгәнне кем эчми, әче тир түгеп тапкан нәрсә түгел әле, төче бит ул. Колхоз бай, сирәк-мирәк берәр капчык фураж сату – урлашу түгел.

Ярар, су буена төшеп, ай яктысында тыныч су өстенә карап утырыйм әле, бәлки коенып та чыгармын. /Тора. Җырлап китә/

Аракыны-водканы
Бик яратабыз аны.
Эчкән чакта бер бидерә,
Бер таз эчәбез аны.

/Каршы яктан Наиль белән Нурия чыгалар/.

**Наиль:** Бу автосаудыргычны көйләү белән сезнең эшне 99% киметәбез.

**Нурия:** Ай-һай, Наиль, барып чыгар микән. Барыбер имчәк төбен безгә җыярга туры килер. Сынау савулары шуны күрсәтте ич.

**Наиль:** Анысы бар, ләкин, савымчылар санын киметергә мөмкинчелек бирәчәк ул. Хәзер 12 савымчы эшли. Алар урынына 6-7 калса, сөтнең үзкыйммәте кимиячәк, эш тә җиңеләячәк. Син ничек, автосаудыргыч ныклап эшли башлагач, фермада калырсыңмы?

**Нурия:** Эш авыр чакта эшләгәч, калам, әлбәттә. Ай, онытa язганмын, колхоз идарәсе, комсомол комитеты укырга җибәрергә карар чыгарганнар. Люция кичә генә әйтте.

**Наиль:** Нурия, мине һич кызганмыйсың син. Укырга китсәң, 4-5 ел ничек түзәргә кирәк. Болай да көтә-көтә көтек булдым инде. Яшьлек үтеп бара.

**Нурия:** Кая үтсен әле, кызлар янына яңарак йөри башладың ич.

**Наиль:** Көлмә,  көлмә. Без 10 класста укыганда, син 5 класста гына идең.

**Нурия:** Хәтереңдәме, язгы каникуллар алдыннан су аркылы мине күтәреп чыгарган идең?

**Наиль:** Сабыйларга шефлык ясый идек. Ә менә сине күтәреп чыгарганым хәтердә калмаган.

**Нурия:** Ә трактор йөртергә өйрәнгәндә, мине таптата язганың исеңдәме? Гаяз абый читкәрәк бормаса, өстемнән трактор белән чыга идең, усал. Менә: "Нуриям, Нуриям, кая син" , - дип йөрер идең.

**Наиль:** Монысы хәтердә. Курыкканымны белсәң иде... Армиядә танк руленә утырган саен күз алдымда синең куркынган гәүдәң тора иде. Бәлки трактор вакыйгасы сиңа беренче хатны язуга сәбәпче булгандыр...

**Нурия:** Ә ул хатның тарихы минем өчен тагын да истәлеклерәк булды. Тәнәфескә чыккач, Гөлшат бөтен классны тутырып: "Нурия, сиңа солдат хаты". – дип кычкырды. Әй, оялдым соң! 10 класс малайлары кемнән ул хат дип теңкәмә тиделәр. Әйтмәдем. Дәресләр беткәнне түземсезлек белән көттем... Кайтып, өйгә дә кермичә, сарайга кереп укыдым. Әллә нинди тылсымлы хат булды ул. Наиль, синең турыңда гына уйлый башладым. Күз алдымнан мәктәпне тәмамлагач синең колхозда тракторчы булып эшләгән чакларың үткәндә күз кысып , елмаеп китүләрең, мәктәп кичәләренә килүең, анда танцыга мине чакыруларың һ.б. үттеләр.

**Наиль:** Үзеңнең дә күңелеңдә булган икән?

**Нурия:** Булмый, мин җиргә тыгып куйган казык түгел ич. Ләкин күңелдә син түгел, башка кеше, тик ул бер дә игътибар итми иде.

**Наиль:** Кызык, кем иде ул?

**Нурия:** Шәһәр кешесе ул хәзер, кирәге дә юк. Ә синең магнит көчең барысыннан көчлерәк булып чыкты.

Аваз: "Коткарыгыз! Коткарыгыз!",

/Наиль, Нурия аваз килгән яка йөгерәләр. Ясәви карт үтә/

**Ясәви:** Имайдыр, башка булмас, суга кергәндер, дөньяның бөтен рәхәтен бергә күрмәкче булгандыр. Әтнәкә, бармый булмый...

/Бераздан Наиль Имайны җитәкләп керә. Имай айный төшкән, ләкин агарган, өс-башы сулы/

**Ясәви:** Мал батар җиренә керер. Кайт, кайт дидем, миңа биредә бесплатный рәхәт, диде.

**Наиль:** Ничек, Имай абый, җиңеләйдеңме?

**Имай:** Һава җитми, тын кысыла...

**Наиль:** Әйдә, бераз йөрик, сиңа хәрәкәт кирәк / култыгыннан тотып йөртә/ Ясви бабай, шулай йөртә тор, мин хәзер. /Нурия янына килә/

**Нурия:** Наил, мин керәм, иртәгә иртәрәк торасы. Сау бул, тыныч йокы!

**Наиль:** Хуш, Нурия! /Имай янына килә/ Ничек, Имай абый?

**Имай:** Ярыйсы, Наиль, рәхмәт. Вәт әкәмәт, сыерлар юындыра торган күпернең кырыена утырдым, аяклар суда торсын дип, суга тыктым. Утыра торгач, йокыга да киткәнмен, авып та төшкәнмен. Вәт сиңа бесплатный рәхәтлек... Теге дөнья рәхәтен күрә яздым бит, кәһаре. Исереккә диңгез тубыктан диләр, дөрес түгел икән.

**Ясәви:** Әтнәкә, суга төшүең, төшеп тә исән калуың әйбәт булды, Имаметдин. Салу гадәтең су төбендә калса яра иде.

**Наиль:** Әйдә, Имай абый, кереп коры киемнәр кийик, юкса туңып, авырып китүең бар./Китәләр. Имай "Әйе, әйе", - дип сөйләнә/

**Ясәви:**Ниләр эшләтми бу шайтан суы. Юныс Фәйзи әйтмешли "биек-биек күперләрдән сикертә".

Пәрдә

## II-пәрдә

Шул ук сәхнә. Иртәнге сәгатьләр. Савымчылар юыналар, җилкәләренә сөлгеләр салып, сөт чиләкләрен беләкләренә элеп, сыер саварга юнәләләр, үзара сөйләшәләр.

**Фәнис:** Наиль, автосаудыргыч ярдәмендә бүген 10 сыер саудырабыз. Техника әзерме синең?

**Наиль:** Техника беренче хәзерлектә, хәзер моторны җибәрәм. Миңа кем булышыр?

**Фәнис:** Нурия. Ул сыерларны урнаштырып йөри. Кара, Наиль, техниканың өстенлеген күрсәт! Җитәр, техника революциясенең беренче карлыгачы өстенлеген исбат итәргә һәм барлык сыерларны автосаудыргыч ярдәмендә саварга идарә рөхсәтен алырга ирешергә кирәк. Юкса, без алган сөттән сыерларны ашату расходларын, биредә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләүне каплаганнан соң бик аз доход кала.

**Наиль:** Үзем дә шул турыда баш ватам: автосаудыргычны ныклап эшкә җиксәк, 5-6 савымчы хезмәт күрсәтү җитәр иде. Аларның хезмәт хакы 11-12 кешегә түләгән хезмәт хакының яртысы гына була бит. Саудыргыч үз бәясен тиз каплар иде.

**Фәнис:** Шулай. Ярый, дус, уңышлар телим/Наиль китә/

Зөлфия керә

Хәерле иртә, Зөлфия!

**Зөлфия:** Исәнмесез! Фәнис, сездә һәр сыерның савым учеты бар бит? Соңгы ай нәтиҗәләрен генә бирегез әле. Алдагы айларныкы да булса, бигрәк тә әйбәт булыр иде.

**Фәнис:** Ярый, иртәнге савуны төгәлләү белән кулыңда булыр.

**Зөлфия:** Мин кичә дә учет кенәгәләрен караштырып утырган идем, ул “Иркә”, “Давыл”, “Назлы” кушаматлы сыерларны ник бу көнгә кадәр тотабыз? Алардан юньле генә бозау да, куандырырлык сөт тә юк ич.

**Фәнис:** Әйдә, әйдә. Зөлфия, бу өлкәдә синең эшне көтәбез. Минем сүз генә үтмәде, инде син йөреп кара. Ярый, сава башладылар ахры, ул тирәгә барыйм әле /Китә/

Машина тавышы. Равиль, Илһам керәләр.

**Равиль:** Я, зоотехник иптәш, эшләр ничек? Исәнмесез!

**Зөлфия:** Исәнмесез, Равиль абый, Илһам абый!

**Равиль:** Автосаудыргыч нишли?

**Зөлфия:** Бүген 10 сыерны саудырабыз, минемчә, техника үз сүзен әйтәчәк. Равиль абый, фермада бик аз сөт бирүче сыерлар 18-20% тәшкил итә. Алардан котылырга иде. Нәсел сыерлары турында уйлашсак, файдалырак булыр.

**Равиль:** Зөлфия, нәсел сыерлары үзебезнең фермада да бар, аларны күздә тотып, нәсел ядросын булдыру – сезнең белән безнең бурыч, шулай бит, Илһам.

**Илһам:** Узган елдан бирле бу нәрсә сүздә генә кала бирде. Быел ныклап эш итәргә кирәк булыр. Зөлфия, ул өлкә синең кулны көтте булса кирәк.

**Равиль:** Менә быел көзгә яңа коровник төзелеп бетә, нәсел ядросын аерым урнаштырырбыз. Нәсел үгезенә дә заявка бирдек, булыр.

**Зөлфия:** Аннан икегез дә биредә вакытта ферманы механикалаштыру турында да фикерләрегезне ишетсәм, яхшы булыр иде. Өзлексез җәй булып тормас, салкыннары белән кыш та килеп җитәр.

**Равиль:** Яңа ферма механикалаштырыла ич. Я, ярый, монысы турында соңрак. Илһам, савымчылар янына барып килик. Зөлфия, бәлки, син дә барырсың?

**Зөлфия:** Әйдәгез, әйдәгез! /Люция йөгереп керә/

**Люция:** Бара торыгыз, Равиль абый, без хәзер. Зөлфия, исәнме?

**Зөлфия:** Исәнме, Люция! Я, хәлләр ничек?

**Люция:** Минем әйбәт, үзең ничек? Күнегәсеңме?

**Зөлфия:** Рәхмәт, акрын бара.

**Люция:** Ә мин сиңа хат алып килдем, биеп җибәр!

**Зөлфия:** Хат? Бир тизрәк!

**Люция:** Сикер, бирәм!

**Зөлфия:** Я, шаяртма, бир инде!

**Люция:** /конверттан адрес укый/ Сарманнан...

**Зөлфия:** Сарманнан, әнидән, йөрәк пәрасыннан! Бир инде/хатны ала, ача/

**Люция:** Я, ярый. Мин савымчылар янына киттем. Син дә озакламассың!

**Зөлфия:** Хәзер, хәзер. /Хатны укый/
“Исән-сау гына яшисеңме, кызым? Хатыңны алдык, эшкә әйбәт кенә керешүеңне, квартирага яхшы кешеләргә урнашуыңны, тормышыңның көйле

генә башланып китүен белеп сөендек. Без хәзергә әйбәт кенә яшәп ятабыз. Ильфак сине бик юксына, иртән торса да, кичен ятса да: “Әнием бүген тагын юк, ул кайчан кайта инде? Дәү әни, мин әниемне бик сагындым бит, беләсеңме?” –ди.
Фәриттән хат килгән иде, адресыңны сораган. Мин кумадым, үзе киткән, гаеп үзендә, ләкин мин тормышны бозу ягында түгел, дигән” /Туктап/
Әйе, Фәрит, өстемнән бик нык көлдең, шуңа китәргә мәҗбүр булдым. Шул кадәргә барып җиттең, сыер тизәге арасында йөреп, силос исе сеңгән хатын белән торганчы, ялгыз яшәвем артык, дидең. Ә бит өйләнгәнче барысына да риза идең. Авылдан килгәнемне дә, бу эшкә теләнеп алынуыңны да белдең. Ә өйләнгәч.../читкәрәк китә, уйлана/.

**Фәнис:** Зөлфия, мин сине дөнья бетереп эзләп йөрим. Менә, син сораган данныйлар, хәтта кичә кичкесе дә бар. Сыерларны савып бетерәләр. Молодец Наиль, автосаудыргычның нәрсә икәнен күрсәтә./Зөлфиянең кулында хат, аның күңелсез икәнен күреп/ Нәрсә, Зөлфия? Сиңа ни булды? Кемнән ул хат? Әллә Казандагы егетеңнәнме?

**Зөлфия:** Юк, Фәнис, аннан түгел әле. Монысы калып торсын. Данныйлар өчен рәхмәт. Савып бетерәләрме әле? Әйдә, шунда барыйк!/Китәләр/

Имай керә

**Имай:** Ай, баш ярыла. Ничек кенә төзәтергә соң бу ватык башны? Әй, ахмак, эчкәнче башыңны төзәтү турында кайгырт, дип ничә тапкырлар әйттем мин сиңа. Шунда бер стаканын калдырмыйча... эчкәндә төбенә төшкәнче эчәсе килә шул, аяктан егылганчы кирәк, ахмак...
Менә хәзер авылга кайтырга, кемнәндер тагын акча теләнергә, Нәҗияне кысарга кирәк. Ә аңа акча каян килсен? Кичә дә “ Булмый, Имай, ике баланы ачтан үтермәм. Ләкин синең белән яши алмыйм”, - дип калды. Эх, бәхетсез баш...Ярый да берәр капчык он озатып булса...

/сөйләшеп көлгән тавышлар/

Атны җигәргә дә авылга. Монда күл суыннан аракы ясап булмас. Киләләр. Сыз тизрәк. Имай! /Китә/

/Равиль, Илһам керәләр, соңрак Фатыйма/

**Равиль:** Димәк, контроль саву һәр сыердан 100-150 грамм сөтнең көн дә җилендә калуын күрсәтте. /Блокнотын алып/ Узган ел бу көннәрдә һәр сыердан 12-15 кг сөт алынган, ә менә быел иң яхшы сыерлар да 15 кг га җиткерә алмый. Сәбәп нәрсәдә?

**Фатыйма:** Илһам энем, сәбәпләрен саный китсәң күп инде. Беренчедән, яшь кеше түгел. Икенчедән, җәй көннәрендә гомерем бередә үтә. Кыш көннәрендә төнге дүрттән дә соңга калмый фермага йөгерәсең. Бар кеше тыныч йокыда, ә син шыгыр-шыгыр, төнге убыр кебек, фермага чабасың. Көне белән төне бергә ялгана. Җитәр, ялгыз хатын дип, 40 яшемә кадәр фермада йөрттегез, инде минем дә кеше кебек кенә эшләп, кеше кебек  ял итәсем килә.

**Равиль:** Фатыйма апа, син заманында алдынгы савымчы идең, исемең район почет тактасыннан да төшмәде, ә хәзер?

**Фатыйма:** Утыз-утыз биш яшькә кадәр тырыштым, хәзер булмый: эше күп, ашы юк.

**Илһам:** Аена 80-90 сумнан ким алганың юк ич, Фатыйма апа!

**Фатыйма:** Хәзер техничка да 60 сум ала. Ә соң сез фермада эшне җиңеләйтү турында уйлаганыгыз, безнең эш сәгатен чутлап караганыгыз бармы?  90 сум алсам, тир түгеп алына ул.

**Равиль:** Уйлыйбыз, Фатыйма апа, уйлыйбыз. Менә яңа коровник тулысынча механикалаштырыла. Без бит сезне ялкау димибез, ә соңгы вакытта эшкә салкын карый башладыгыз, монысы факт /блокнот карый/

**Фатыйма:** Ярый, ярый, аутасаудыргыч дисезме әле, аны худка җибәреп, эш җиңеләя башлагач, безнең кирәгебез дә калмас. Авыр чакта тарттыгыз, рәхмәт, хәзер эш аутаматта, белемлерәк кешеләр кирәк, читтәрәк торыгыз диярсез.

**Илһам:** Автосаудыргыч белән эш итеп, без савымчыларның эшен җиңеләйтүне генә түгел, икенче әһәмиятлерәк нәрсәне дә – сезнең сменалап кына эшләвегезне дә күздә тотабыз. Механикалаштыруның төп максаты – авыр кул хезмәтеннән коткару.
Шунысы кызганыч, Фатыйма апа, авыр вакытта менә дигән эшләп тә, эшләр җиңеләя төшкәч, саву саен һәр сыер җиленендә 150 грамм сөт калдыру – сезгә хас түгел.

**Фатыйма:** Аутаматыгыз дә калдыра ич, безгә дә калдыру гаеп түгел. Бармаклар арый, икенче тапкыр саумыйм, сәбәбе шул.

**Илһам:** Автосаудыргычтан соң җиленгә массаж ясау, аннан калган сөтне саву табигый икән, сезгә дә савып карау кирәк. Ә ферманы механикалаштырудан соң сез эшсез калмассыз , әлбәттә.

**Равиль:** Узган елгы күрсәткечләреңне быелгылары белән чагыштырып тордым, быел савым түбән синең, факт.

**Фатыйма:** Әй, энем, энем, мин дә кеше бит, ник гел эш кенә таләп итәсез соң? Минем эчке дөньям белән кызыксынганыгыз бармы? Сезгә сөт кирәк, калганына төкерәсез сез! /читкәрәк китә/. Отпуск турында нәрсә әйтерсез? Ике ел ял күргән юк. /Китә/.

**Илһам:** Алар хаклы. Чыннан да без кешегә эшче итеп кенә карыйбыз. Аларның күңелле ял итәселәре дә килә бит.

/Фәнис, Наиль, Зөлфия һәм Люция керәләр, Люция савым нәтиҗәләре буенча чыгарылган "Яшен" элә/

**Фәнис:** Әйттем ич, автосаудыргыч үзенаклады дип, так и есть, бер Нурия 10 сыер белән бик тиз һәм бик җиңел эш итте, 25-30 сыерны сава алмас идемени?

**Наиль:** Сүз дә юк, савар иде.

**Зөлфия:** Автосаудыргыч белән алынган сөт чиста була, I-группа белән генә китәчәк, монысы да әһәмияткә ия нәрсә.

**Наиль:** Равиль абый, иртәгә 40 яки 50 сыерны автосаудыргыч белән саудыруга сез каршы түгелме?

**Равиль:** Бик тиз булмасмы? Сыерларның да күнегүе кирәк бит.

**Илһам:** Минемчә, моннан курыкмаска, саудырырга кирәк. Аның нәтиҗәләре бик тиз күренер. Безнең 4 савымчы 2 еллык отпуск алмаган, чиратлап шуны бирә башларга, минемчә.

**Равиль:** Монысы факт. Кемнәр алмаган әле безнең, Фәнис?

**Фәнис:** Фатыйма апа, Гөлшат, Нурия, Гилмиса апа.

**Люция:** Беренче чиратта ялны Нуриягә бирергә, укырга керү өчен хәзерләнергә кирәк аңа.

**Наиль:** Анысын үзаралай хәл итәрбез,Люция, очномы, заочно укыргамы?

**Илһам:** Әллә сезнең роман чынга әйләндеме, Наиль?

**Наиль:** Һәркемнең  башыннан үтә торган хәл, Илһам абый.

**Равиль:** Без болай итик, Фатыйма апа белән сөйләшеп, ана Кавказга туристик походка җибәрик, дөнья күреп кайтыр. Люция, кыен булса да, Фатыйма апаны чакырып килегез!

**Люция:** Хәзер, Равиль абый /китә/

**Илһам:** Ә Гөлшатны ял йортына җибәрик. Безнең Берсутка путевка бар ич.

**Фәнис:** Гөлшатка обязательно кирәк. Тик шунсын онытмагыз, барысын да җибәреп бетереп, сыерларны саву миңа калмасын.

**Наиль:** 50-60 сыерны Нурия белән икебезгә калдырыгыз, сөте дә кимемәс, авырсынмыйча гына саварбыз да. Ярый, мин агрегатны чистартып килим әле/китә/.

Фатыйма керә.

**Фатыйма:** Нәрсә бар тагын? Сөт кирәкме?

**Илһам:** Юк, Фатыйма апа, сөт түгел, сезгә ял бирү турында.

**Фатыйма:** Әйттем ич, мин сезгә, аутамат заманы, сезгә ял кирәк диярсез дип.

**Равиль:** Фатыйма апа, без сезгә 2 еллык отпускагызны бирмәкче булдык. Кавказга путевка бар иде, 20 көн ял итеп кайтыгыз!

**Фәнис:** Бар, бар, Фатыйма апа!

**Фатыйма:** Түләпме соң ул? Минем бер дә чыкканым юк. Я адашып бетәрмен, рәхмәт, кирәкмәс.

**Илһам:** Курыкма, районнан 4 кеше буласыз, адашмассыз. Ә путевканы түләүсез бирәбез.

**Фатыйма:** Тәнкыйть тиз арада керде үзегезгә. Ял турында да уйлый башладыгыз.

**Равиль:** Без аны уйлыйбыз, бу вакытка кадәр мөмкинлек булмады бит әле.

**Илһам:** Җавабыңны иртәгә әйтерсең. 3 көннән китәргә. Районнан кемнәр барасын белешеп, хәбәр итәрмен.

**Фәнис:** Әйдә, өеңне Гилми апа карап торыр, мал-туарың юк. Йөреп кайт, Фатыйма апа.

**Фатыйма:** Әче телем өчен булдымы бу? Миннән дә яхшырак эшләүчеләр дә бар, аларны җибәрегез!

**Равиль:** Һәч кенә дә алай түгел. Киләчәктә тырышып эшләү өчен көч җыеп кайтырга җибәрәбез. Яшьләр дә барырлар, элек ветераннарны тәэмин итик әле.

**Фатыйма:** Ярый, рәхмәт, җавабымны иртәгә әйтермен /китә/

**Илһам:** Равиль, иртәгә үк 50 сыерны автосаудыргыч белән саудырырга рөхсәт бирергә. Минемчә. Наильгә оптуск алганчы Нурия булышыр.

**Равиль:** Ярый, Фәнис, тик төгәл эшләгез. Ике көнлек нәтиҗәне хәбәр итәрсез. Ярый, иптәшләр, без икенче бригадага киттек, армый эшләгез!

**Фәнис:** Хушыгыз, рәхмәт!

ПӘРДӘ

## II-пәрдә
## II –нче күренеш

*Ясәви картлар өе. Бер якта хуҗалар, икенче якта Зөлфия бүлмәсе. Кырда кровать, уртада өстәл. Пәрдә ачылганда Зөлфия хат укый.*

**Зөлфия:** “Зөлфия, хатын-кызның ихтыяр көче шундый зур булуы минем күз алдыма да килми иде. Син принципиальность күрсәтәм дип семьяга, балага төкереп карадың, тормышны бозды. Хәзер өчебез өч якта. Ильфак әтисен, әнисен күрергә тилмерә. Хәзер дә аңыма килә алмыйм – ничек шул адымны ясый алдың син?
Кайт, Зөлфия, мин элеккеге гадәтләремне ташладым, эчмим. Сиңа да эш бар, тик баланы урнаштырыр урын юк...”
Әйе. Өчебез өч якта. Эх, Фәрит, Фәрит! Син һаман да Казанга чакырасың, Булмас ахры. Шәһәрдә яшим дип яраткан эшемне ташлый алмаганымны беләсең ич. Әгәр дә син баштагы хыялларыңны тормышка ашырсаң... Элек пединститутта укыдың. Бала-чага белән чәч агартыр хәлем юк, дидең. III-нче курстан ташладың, авыл хуҗалыгы институтына барып кердең, инженер-механик булам, дидең. Сөендем. Өстәмә имтиханнар тапшыра-тапшыра җафа чиктең. Тәмамладың, инженер да булдың. Ә аннан :”Юк, тәүлекнең 24 сәгатен дә эшләп йөрер хәлем юк, авылга китмим”, - дидең. Ә мин, җүләр, хыяллана идем. Икебез дә авылга китәбез, беребез – инженер-механик. Икенчебез – зоотехник, имеш. Эштән салып кайта башладың, тавышың да көчәйде, мин әрәмтамакка әйләндем. Җүләр, дипломлы җүләр, мин шуңа риза булып тордым. Син хәзер дә шул тормышны телисең...

Гыйльми керә.

**Гыйльми:** Кызым, аш өлгерде, тамак туйдырып алыйк. Көн озын эштә, кайткач та утырып ашаганың юк.

**Зөлфия:** Хәзер, хәзер, апа җаным, хәзерли тор, мин тиз...

Гыйльми чыга.

Әйе, тормышны кайнар мәхәббәт белән генә алып барып булмый икән, икеңнең дә бердәй теләге, бердәй омтылышы да кирәк икән.Тормышны башлаганда боларның берсе турында да уйланмаган /китапларын җыештыра/.Ярый, тамак туйдырып алыйм./Чыга/.

Наиль белән Нурия керәләр.

**Наиль:** Мөмкиндер?

**Нурия:** Кер, әйдә, яртылаш кергәч, рөхсәт сорап торасың. Бә... беркем дә юк икән.

**Наиль:** Ярый, йорт хуҗасын көтик. Бу ялгыз бүлмәне акча биреп тә таба алмассың.

**Нурия:** Әй, усал, ялгыз калуны чамалап кына тора. Алай булгач, Пятница кебек, кеше юк җирдә яшә син.

**Наиль:** Үзем генә түгел, синең белән. Икәү булсак, Каф тавы артына китәргә дә риза.

**Нурия:** Китмичә кешеләр арасында яшә әле. Кешесез ничек гомер итәргә кирәк?

**Наиль:** Я, кил әле, нечкә билләреңнән бер кысып кочаклыйм үзеңне! Менә, шашкан, шул гына җитми иде.

/Наиль йөгереп килә, кочаклап алам дигәндә генә Нурия ычкына, куышалар/. Җитәр дим, Гыйльми апа өйдәдер, килеп чыкса.

**Наиль:** Чыкса чыгар, мин сине галәм алдында кочарга да оялмыйм. /Эләктереп ала, кочаклый, үбә. Гыйльми чыга, боларны күреп, кире керә, бераздан, тамак кырып, тагын чыга/.

**Гыйльми:** кунаклар бар икән. Әйдүк, әйдүк, балалар! Аш та өстәлдә, тамак туйдырып чыгыгыз.

**Наиль:** Без ашамыйча да тук, Гыйльми апа, рәхмәт. Зөлфия янына гына дип кергән идек.

**Гыйльми:** Хәзер чыгар/китә/.

**Нурия:** Мин кереп уку ягында...

**Зөлфия** /чыга/: Ә-ә, кунаклар бар икән, исәнме, Наиль, исәнме, Нурия! Әйдәгез, үтегез!

**Нурия:** Рәхмәт, Зөлфия апа, без озакка түгел, ләкин безнең өчен бик җитди мәсьәлә буенча кергән идек. Вакытыгыз ничектер бит...Бүген клубта Әлфия Авзалова концерты була, ишеткәнсездер. Сезгә билет та алып кердек.

**Зөлфия:** Рәхмәт, дуслар! Ә сезнең өчен бик әһәмиятле мәсьәлә нәрсә инде ул?

**Наиль:** Зөлфия...

**Нурия:** Әз генә туктап тор инде, элек мин сөйлим.

**Наиль:** Сөйлә, сөйлә...

**Нурия:** Зөлфия апа, мин быел колхоз идарәсе, комсомол комитеты "Таң" колхозы степендиаты итеп, ветеринария институтының зоотехника факультетына җибәрергә карар чыгарганнар. Мин моңа шатланып риза. Сез ничек карыйсыз?

**Зөлфия:** Бик әйбәт, мин барырга тәкъдим итәр идем.

**Наиль:** Баруын барырга, ә мин?

**Нурия:** Әз генә туктап тор инде!

**Зөлфия:** Сезнең нәрсә, әллә тормыш кору теләге бар идеме?

**Нурия:** Шулайрак иде шул. Утлы табада кыздыргандай, кыздыра быел, көзгә өйләнешик дип теңкәмә тиеп бетте. Минем укырга керәсем килә, тормышка чыгарга иртәрәк тә бит әле.

**Наиль:** Сиңа иртәрәк булса, миңа соңгарак кала бара шул. Кеше читтән торып та укый. Мин сиңа бөтен мөмкинлекләрне дә тудырырмын.

**Зөлфия:** Анысын үзегез хәл итәрсез, тик мин кереп укуны яклыйм. Болай сиңа 3 камыт кияргә: эшен дә эшләргә, кичләрен укырга да, ир дә тәрбияләргә туры киләчәк. Наиль, син аңа читтән торып укуны җиңел булыр дисеңме?

**Наиль:** Һич юк, ләкин мин аңа булышырмын. Ул мине түгел, мин аны тәрбияләргә уйлыйм.

**Нурия:** Башта шулай тәртә буе вәгъдәләр бирәсез инде сез...

**Зөлфия:** Наиль, ә син укырга уйламыйсыңмы?

**Наиль:** Картая барам ич, Зөлфия.Хәзер миңа 25 яшь, 5 ел кереп укысам, 30 дан артып китә бит. Хәзер эшләргә дә эшләргә инде.

**Зөлфия:** Ай-һай иртә картаясың, егет. 30 яшь – сабыйлык чоры бит әле. Аның өстенә синдә практика зур хәзер.

**Нурия:** Ул турыда бөтенләй уйлашканыбыз юк иде шул.
Наиль: Урта мәктәпне тәмамлаганга да 7 ел үтте, күп нәрсә онытылган. Керү имтиханын бирә алмам.

**Зөлфия:** Синдәй егеткә үз кимчелеген җиңә алмау – матурлык түгел. Наиль, минемчә, икегезгә дә укырга кирәк. Син бит, Наиль, техниканы бик яратасың, машина күрсәң дөньяңны онытасың.

**Нурия:** Техника күрсә, филдәй мине дә күрми ул

**Наиль:** Яратам шул, шуңа эшлим дә.

**Зөлфия:** Ник соң практиканы теория белән бәйләмәскә, инженер- механик булмаска?

**Нурия:** Кара, кара, бик әйбәт киңәш бит әле бу. Әйдә, Наиль, бергә хәзерләнәбез, бергә китәбез.

**Наиль:** Сезгә шулай, ә ялгыз әниемне 5 ел буе тагын миңа хезмәт иттерергә телисезме? Ул бит минем өчен гомерен, бөтен көчен, үзе әйтмешли, бурычка бирде, миңа аны түли башларга кирәк. Биш ел яшәрме соң ул?

**Зөлфия:** Ана баласы хакына, аны кеше итәр өчен үз гомерен багышлый, без, балалар гына, моны бәяли белмибез. Ана йөрәге турындагы легенданы беләторгансыздыр. Сөйләшеп карагыз, минемчә, Фәүзия апа каршы булмас. Икегез дә китсәгез, аның хәсрәте дә кимрәк булыр. Нурия белән мөнәсәбәтегезне беләдер бит?

**Нурия:** Белә, күргән саен: “Кызым, безгә кайчан киләсең инде?”- ди.

**Наиль:** Ә миңа бу сорау көненә 10-15 мәртәбә бирелә. “Башлы-күзле булып, матур тормыш корып җибәргәнегезне күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем”, - ди.

**Зөлфия:** Әгәр икегез дә бергә китсәгез, икесе дә бергә әле, дип аның күңеле тынычланыр иде.

**Нурия:** Рәхмәт, Зөлфия апа,  уйлашабыз да, килешәбез дә.

**Наиль:** Әни ни дияр бит әле.

**Зөлфия:** Бергәләп, сөйләшеп карагыз, Фәүзия апаны үзем дә күрермен әле.

**Наиль:** Китәргә туры килсә дә өйләнмичә китмим.

**Нурия:** Я, ярар инде, уйлашырбыз. Зөлфия апа, концерт 8 дә башлана, килерсез бит.
**Зөлфия:** Барырга тырышырмын. Билетыгыз өчен рәхмәт!

**Наиль:** Ярый, Зөлфия, хәзергә хушыгыз, киңәшегез өчен, минем файдага ук булмаса да, рәхмәт.

**Нурия:** Кичкә кадәр, Зөлфия апа!

**Зөлфия:** Хушыгыз, онытмагыз, кергәләгез.

/Нурия, Наиль китәләр/

Безнең дә моңа охшашлы вакытлар бар иде бит. Ә хәзер өчебез өч якта... (уйланып җырлый)
Очраштык без айлы бер кичтә
Язгы сулар ташып акканда,
Вәгъдәләр бирешеп шул төндә
Аерылдык иртән ай батканда.
Өзелеп сөйдем, яндым-көйдем
Синең мәхәббәт утыңда,
Кайнар хисләр кая калдылар,
Йөзәм хәзер сагыш утында.
Фәрит, Фәрит... Аңлашмадык ахры. Вакытлы һәм очраклы гына булдымени бу мәхәббәт? Мин көтәм, сабыр итәм, мәхәббәтең сүнмәсә килерсең... Килерсең бит, Фәрит? Ильфак та ятим булмас иде.

Гыйльми чыга.

**Гыйльми:** Кызым, мин түбән оч Фатхияларга барып кайтыйм әле, чыгарга уйласаң, ишекне бикләп, ачкычны ярыкка тыгарсың.

**Зөлфия:** Ярый, ярый апа, бу хатны гына салып җибәрмәссеңме?

**Гыйльми:** Бир. Клубка барасыңмы, кызым?

**Зөлфия:** Барырмын дигән идем, апа. Әллә берәр эш бармы?

**Гыйльми:** Юк, юк, кызым, барып кайт дип әйтмәкче идем, килгәнеңә ике ай – эштән башка бер кая да чыкканың юк. Яшь кешегә килешми, кызым.

**Зөлфия:** Гыйльми апа, нинди хат алып барганыңны беләсеңме?

**Гыйльми:** Хат – хат инде ул.

**Зөлфия:** Ачуланма, әйткәнем юк иде. Әниемә ике яшьлек баламны куеп килдем. Мин аларны бирегә чакырып язган идем. Әни дә ялгыз. Сыярбыз бит, апа.

**Гыйльми:** Сыярбыз, сыярбыз, кызым, урын тар булса да, күңелебез иркен. Ачуланма, Зөлфия, ничек болай соң әле бу? Мин бит сине яшь җилкенчәк дип уйлаган идем.

**Зөлфия:** Ник? Ачуланмыйм. Тормыш шулай килеп чыкты инде, апа. Иремнең шәһәрдән аерыласы килмәде, ә мине авыл тартты. Укуны тәмамлагач, ике ел буе эшсез торырга туры килде: бала карар кеше булмады, аннан Казанда безнең профессия кешеләренә эш юк.

**Гыйльми:** Әниеңне ялгыз дидең ич, ул бармадымы?

**Зөлфия:** Без иремнең әнисендә тордык, ул эшли иде. Иремнең нигәдер әнине китертәсе килмәде, квартира да кечкенә.

**Гыйльми:** Кызын яраткач. Анасын да яратырга кирәк иде.

**Зөлфия:** Тора-бара кызы да әрәмтамакка  әйләнә башлады шул. Салгалады. Әнисе миңа, гомумән, кырын күз белән карады, кыскасы, яратмады.

**Гыйльми:** Алай... Синең  авыр вакытың икән шул, кызым. Үзең киттеңме, җибәрделәрме?

**Зөлфия:** Күзле көек булганчы, үз көнемне үзем көтәрмен дип, китәргә булдым.

**Гыйльми:** Ә ирең?

**Зөлфия:** Үзен күбрәк көйләтте шул, соңарак миңа үзенең хезмәтчесе итеп карый башлады. Әнисе аны : “Менә дигән Казан кызы беткән идеме сиңа?” – дип әрли иде.

**Гыйльми:** Алай икән...

**Зөлфия:** Мин аңа еш кына: “Авылга  китик, беркемнең дә үлгәне юк”, - дип тә карадым. Ризалашмады. Казанда эшкә керергә мөмкинлегем булмады, баланы да яслегә урнаштыра алмадым.

**Гыйльми:** Алай... Ярар, менә дигән Казан кызы белән кавышып яшәсен. Үлмәбез, кызым, теттереп гомер итәрбез. Авылда да менә дигән яшьләр бар, үзең дә бар яктан килгән, бәлки, башлы-күзле булырсың... Аяк астында туфрак булып яшәгәнче, үзеңә үзең хуҗа булу мең өлеш артык.

**Зөлфия:** Мин дә, ул да бер беребезне бик ярата идек...

**Гыйльми:** Яратса, кадереңне белер иде. Яратуы шундый гына булган аның.

**Зөлфия:** Мин киткәч эчми башлаган. “Икегезне дә бик сагындым, кайтыгыз” дип хат язган.

**Гыйльми:** Ай-һай, кызым, ничек булыр икән? Сабыр ит, сөюе хак булса, килер, килешерсез, әнисе Казан кызына өйләндереп куймаса.

**Зөлфия:** Ул башта һич андый түгел иде, шунысы – бер урында утырып кына эшли алмый. Бер ел элек укуын бетерде, хәзер өченче эшкә керде инде.

**Гыйльми:** Эше төпле булмагач, күңеле күбәләктәй оча торган кешедер ул. Я, ярый, кызым, иртәгәсе хәерле. Ә баланы, әниеңне колач җәеп каршы алырбыз. Бик әйбәт. Безгә дә иптәшләр булыр.

**Зөлфия:** Рәхмәт, Гыйльми апа!

**Гыйльми:** Борчылма, кызым, килер, килмәсә – аптырама... Ярый. мин барып кайтыйм инде. /Китә/

Зөлфия ялгыз.

**Зөлфия:** Бәлки, Гыйльми апа хаклыдыр. Синең җитешсезлекләреңне , кире якларыңны көчле мәхәббәтем пәрдәсе каплагандыр. Шулай ялгыштыммы мин синдә?
Ә Фәнис? Нәрсә көтә ул миннән. Бу вакытка кадәр чынбарлыкны әйтеп бирергә кыюлыгым җитмәде. Аның күңеленә авыр булмаслык итеп, җайлап кына әйтергә – алданып йөрмәсен. Чын күңеленнән бирелеп йөри.
Хисләргә бирелеп киттем, ахры. Узган бишкөнлектә алынган сөтнең нәтиҗәләрен җыясы, дуңгызлардан алынган артымны исәпләп, көнлеген чыгарасы бар. (Утыра, дәфтәрләрен ача, счет ала, исәпли).
Әйе, автосаудыргыч үзен аклый, Фатыйма апаның, Гөлнараның юклыгы сизелми дә, нәтиҗә дә әйбәт. Молодец, Наиль, молодец, Нурия! Сезне җибәрү никадәр кыен булачак. Әллә бармаска өндәргәме? Юк, юк, укысыннар. Гөрләтеп укырлар, дөбердәтеп эшләрләр.

Җәй дә үтеп бара, ә фермалар каралмаган. Ничек кенә сыерларны яңа сарайга күчергәч, искесен механикалаштырырга? Соңгы чиктә азык бирү, тирес чыгаруны булса да көйләргә иде. Илһам абый белән дә, Люция белән дә киңәшеп карыйм әле, колак салмый калмаслар.

Ишек кагалар. Бәйрәмчә киенгән Фәнис керә.

**Фәнис:** Рөхсәтме, Зөлфия?

**Зөлфия:** Керегез. Фәнис.

**Фәнис:** Син һаман эштә... Концерт башланырга бер генә сәгать кала. сине алмага кергән идем.

**Зөлфия:** Рәхмәт, Фәнис, ләкин мин сезнең белән бара алмыйм, гафу итегез.

**Фәнис:** Эх, Зөлфия. Зөлфия, ник шул кадәр ялындырасың? Мондый кызны очратканым юк иде. Ник качасың миннән, әллә тиң күрмисең, әллә...

**Зөлфия:** Һич алай түгел, башка сәбәбе бар, Фәнис. Мин, сез уйлаганча, кыз бала түгел, бала анасы /ояла төшә/

**Фәнис:** Шаяртма инде. Минем күңелне һич аңларга теләмисең, һаман телгәлисең, Зөлфия.

**Зөлфия:** Һич юк, Фәнис, дөресен әйтәм. Мин дә утын түмәре түгел, синең хисләреңне аңлыйм. Ә йөрәк телгәләрлек нигез юк кебек.

**Фәнис:** Барысы, барысы да телгәли мине...

**Зөлфия:** Телгәләнмә, Фәнис, мин – ир хатыны. Мә, укы /Хат бирә/

**Фәнис:** /Укый, башын тота. Зөлфия иеп тора. Тынлык/ Менә шулай Фәнис, ачуланма...

**Фәнис:** /Зөлфиягә омтыла/. Зөлфия, мин сине барыбер яратам. Неужели, синең мәхәббәтеңә лаек түгел мин?

**Зөлфия:** Лаек, Фәнис, ләкин күрәсең, минем күңел буш түгел, мин иремне өзелеп яратам.

**Фәнис:** Яраткач ник ташлап киттең? Яратмагансың син аны. Мин, мәсәлән, һич синнән аерылмас идем. Шундый хатынны китәргә мәҗбүр иткәч, ерткыч булган ул.

**Зөлфия:** Моңа тормыш судья, Фәнис. Ачуланма, бара тор. Мин соңарак барырмын. Ә безгә бергә йөрү гомумән килешми. Егеттәй егет үз тойгыларын җиңәр, минемчә. Сау бул, Фәнис!

**Фәнис:** Зөлфия, нинди генә булсаң да, мин сине яратам, синнән башка тормыш юк миңа. Аңла моны! Кайгы-хәсрәтең, шатлыгың булса да яшермә, әйт – барысы да уртак. Синең уйларың белән яшәү – минем өчен бәхет ул. /Китә/

**Зөлфия:** Карау белән гашыйк булырсың үзенә. Эзлекле, принципиаль егет. Бәлки тормыш иптәшен шулай сабырлык белән эзлидер. Күңел дигәнең күлмәк түгел шул, теләсә кемне яратмый. Өч ел элек армиядән кайткан, бер кыз белән дә йөрмәгән, ә миңа, хатын кешегә, мәхәббәте төшкән. Әйе, моның күңеле күбәләккә ошамаган, төпле күренә. Бәхетле булыр бу егет. Яшьрәк, буш чаклар булса, үзем дә кире какмас идем. Булмый шул, ярамый.
Фәритем килер, улыбыз да順 янындабыз булыр. Без дә бәхет һәм шатлык диңгезендә йөзәрбез... Ә килмәсә?
Ярый, сөйләнә торгач, байтак вакыт узган, миңа да барыргадыр ләбаса. Киенеп чыгыйм да барырга. Сагыш моңнарын, тормыш җырларын ишетеп кайтыйм.

ПӘРДӘ

**II-пәрдә**
**II- күренеш**

/Шул ук бүлмә. Вакыйга 10-15 көн соңрак бара/
Ясәви карт белән Гыйльми карчык посылка ачалар.

**Ясәви:** Карчык, самоварыңны яңарт. Җимешләре белән яндырып чәй эчеп җибәрербез.

**Гыйльми:** Тукта әле, җимеше бармы, юкмы, ач инде. ач.

**Ясәви:** Әтнәкә, малаебыз булмады дип үкенмим: кызларыбыз малайлардан да яхшырак булдылар. Ай саен көне-сәгате белән килеп кенә тора. /Ача/

**Гыйльми:**/ситец чыгарып/Миңа күлмәклек ахры. Ай, рәхмәт яугырлары, әле тегелмәгәннәре дә ята бит. Ник расходланырга инде. Пенсиям дә җитәрлек, атагыз эшләп тора. Әй, балалар, балалар...

/Ясәви полиэтилен капчык тартып чыгара/

**Ясәви:** Җимеш ягында яшәп, җимеш җибәрәчәкләренә шикләнәсең тагын. Әтнәкә, рәхмәт, балалар. Карчык, бар инде самоварыңны җырлатып җибәр!

**Гыйльми:** Хәзер, хәзер/китә/

**Ясәви:** /100 граммлы бутылка чыгарып/ Әтнәкә, молодец, кияү, бабаңны онытмыйсың. Бүген алҗып та кайткан идем, канны таратып җибәрергә әйбәт булды. Йоклап та алсам, каравылга барганчы чын кеше булам.

/Гыйльми чыга, Ясәви бутылканы яшерә/

Әйдә, карчык, тизрәк бул инде. Кара әле, картыңа чалбар җибәргәннәр. Ай, рәхмәт, кияү, рәхмәт, кызым!

**Гыйльми:** Зөлфия кайтканны көтмибезме? Болай әйбәт булмас бит.

**Ясәви:** Ул кайткач, тагын яндырып эчәрсез. Мин алҗып кайттым, карчык, төне тынгысыз булды – бер сыер да бозаулады...

**Гыйльми:** Арсаң да, карт, самоварны гына алып чык инде, җырлый ахры...

**Ясәви:** Әйдә, әйдә, өстәлеңне карый тор! /китә/

/Гыйльми өстәл хәзерли. Ясәви самовар күтәреп чыга, өстәлгә куя. Утыралар/ Әтнәкә, карчык, кияүләр әйбәт бит, онытмыйлар/бутылканы чыгара/

**Гыйльми:** Әй, җүләрләр, җүләрләр, 60 ка җиткән кешегә шул шайтан суын җибәрмәсәләр нәрсә булган...

**Ясәви:** Әтнәкә, карчык, аңламыйсың. Мин бит аны пусилкәдә килгәч кенә кулланам, харам түгел ич. Яшәреп китсәм, сиңа да начар булмас иде.

**Гыйльми:** Яшәреп, кызлар артыннан китәр иде бугай, китми тор әле, картлач.

**Ясәви:** /йомры ала, сала/ Әллә, карчык, сиңа да әзрәк тамызыйммы? Икәүләп яшәрсәк, бигрәк әйбәт булыр иде.

**Гыйльми:** Әстәгыфирулла, авызыңнан җил алсын, карт җүләр.

**Ясәви:** /җимеш ала/ Карчык, авыз ачам, мең яшә: син булмасаң, кызлар булмас иде, кызсыз кияү булмас иде. Кияү булмаса, монысы да булмас иде.

**Гыйльми:** Әйдә, бигрәк күп сөйләдең, эчсәң эчеп куй да, аша!

**Ясәви:** Әллә авызыңнан су киләме? Исән бул, карчык, сәламәтлеккә булсын! /Эчә/ Эх.. әтнәкә, бигрәк каты икән /җимеш каба/. Әллә йолдызлы булган инде.../ашыйлар/. Кара, карчык, хатлары юк идеме?

**Гыйльми:** Үзең ачтың ич. Чалбар кесәңне кара әле.

**Ясәви:** /карый/ Менә бит. Әтнәкә, тәртибен беләләр /өстәл тартмасыннан күзлек ала, укый/
“Кадерле әниебез, әтиебез! Күп сәлам җибәреп, сәламәтлек, озын гомер телибез. Без хәзергә исән-сау, үзебез эштә, балалар ялда. Алай да сезгә күп сәлам җибәрәләр. Әти, 60 яшең тулу белән котлыйбыз, сәламәтлек телибез. Юбилеең  хөрмәтенә тотып куярсың-затлысын салабыз. Безне дә үзегез янында дип хис итегез.
Әни, сиңа да күлмәклек салдык, сәламәт ки! Безнең тормышны яктыртып озак яшәвегезне теләп, киявегез белән кызыгыз Фәүзия!
Бәй карчык, онытканбыз бит! Бүген числоның ничәсе соң әле?

**Гыйльми:** 12 август, онытканбыз бит,карт! Туган көнең кичә булган. Соң булса да уң булсын, котлыйм үзеңне/маңгаеннан үбеп ала/.

**Ясәви:** /дәртләнеп/ Әтнәкә, кызлар искә алмаса, онытып уздырган булыр идек. Син үзең дә сыйламадың әле. Кичәге көнне сызып куйыйк, бүген бәйрәк итик, карчык. 60 яшь бит, пенсия яше. Әтнәкә, мин эшкә киткәнче, коймак ашатып җибәрерсең – бәйрәме шул инде аның.

**Гыйльми:** Берәр көнгә бармый торсаң да ярар, бәйрәмең бит.

**Ясәви:** Булмас ахры, әтнәкә, исерек Имай белән буталып йөрмәсәм, туган көнем искә төшәр иде. Кәһаре, эчә дә эчә дибез, үзенекен түгел, халыкныкын эчә икән. Ярый күрдем, бер капчык онны мөдир чоланыннан суырды да чыгарды. Әйттем... Идарәгә җиткердем.
Начарлык эшләдемме, яхшылыкмы? Яхшылык. Ни өчен? Юлдан чыкмасын, өчен, семьясы, үзе хакына, колхоз милкен саклау өчен.

**Гыйльми:** Нәрсә сөйләнәсең, карт? Әллә башыңа киттеме?

**Ясәви:** Әтнәкә. Зәһәр булды бу, тәпи бармакларына кадәр үрмәли. Утырган җирдән оеганчы, ятсам әйбәтрәк булыр, карчык. Сиңа да балаларга да рәхмәт! Вәт бәйрәм булды бу/тора башлый/. Карчык, хәзер булыша алмыйм, ачуланма инде. Зөлфия дә кайтып җитәр, әйбәтләп сыйла /акрын гына китә/.

**Гыйльми:** /чәй эчә, аннан җыештыра башлый/. Рәхмәт, балалар, атагызны онытмагансыз, мине дә. Картаябыз, миңа 57, картка 60 сукты. Ул да пенсиягә чыккач , ике кызыбызга да барып, дөнья күреп, әйләнеп кайтырбыз әле. Өйгә күз-колак булырдай кешебез бар, әнисе дә килсә, бигрәк әйбәт булыр.

Ишек шакыйлар

**Имай:** /керә/ Исәнме, Гыйльминиса түти!

**Гыйльми:** Шөкер, шөкер, Имаметдин. Ни йомышлар белән йөрисең?

**Имай:** Гыйльминиса түти, җаным, зинһар кичкә кадәр бер тәңкә ярым биреп тор, ә?

**Гыйльми:** Нишлисең ул тәңкә ярым белән? Ваклап әҗәткә акча сорап йөрү ир-ат эше түгел ул.

**Имай:** Күршелек хакына, хәлемә кереп кенә. Хәсрәтем зур, түти: бүген Наҗия, ике малайны алып, туталарына китте. Зинһар, бир, үтермә, кичен түләрмен.

**Гыйльми:** Китәр шул. Авырлыктан, кызудан таш та ярыла, хатын-кыз – таш түгел. Үз көнең турында уйлап, үз кәефеңне генә күреп йөрисең. Бик яхшы эшләгән, азрак акыл булыр. Тәңкә ярым белән нишлисең?

**Имай:** Башым ярыла. Зинһар, үтермә түти җаным. Бодай кирәк булса, бодай, арыш дисәң, анысы да була.

**Гыйльми:** Бәйләнчек эт булдың, оялмыйсың да. Кырыкның теге ягына үрмәлисең, әле дә акыл чамалы – тормыш турында уйлар идең. /Кесәсеннән акча чыгара, Имай ташлана/

**Имай:** Ай, рәхмәт, мең яшә,Гыйльминиса түти /кулларын уалый/

**Гыйльми:** Соңгысы булсын, башка акча сорап аягыңны да атлыйсы булма, җүнсез.

**Имай:** Соңгысы, соңгысы, терелттең, мең яшә. Әллә ятып табаннарыңны үбимме?

**Гыйльми:** Телеңә салынма, күземнән югал. Сасыган кәҗә тәкәсе исләре килә. Ничек түзгән бу Наҗия, мескен.

**Имай:** Мин киттем, мең яшә, күрше! /Китә/

**Гыйльми:** Һай, бу күңелне! Тукта әле, бу исереккә нигә акча бирдем соң мин, тагын эчәргә бит/ишеккә таба юнәлә, аңа каршы пачтальон кыз белән Фәрит керәләр/

**Почтальон:** Исәнме, Гыйльми апа! Бу тәти абый сезне эзләп йөри иде, алып килдем /газеталар актара/

**Фәрит:** Исәнмесез, апа!

**Гыйльми:** Әлегә шөкер, улым, кем дип әйтим соң? Олайдым ахры, күзләр элдереп бетерми, күргән дә кебек тоям, әмма кем икәнеңне әйтә алмыйм.

**Фәрит:** Апа, мин Казаннан, Зөлфиянең ире /почтальон аптырап карап тора/

**Гыйльми:** Ә-ә, чыннан да тәти егет икәнсең. Үт әйдә, үт, чишен.

**Фәрит:** Рәхмәт, апа /үтә, чишенә башлый/

**Почтальон:** Гыйльми апа, бабай өйдә юкмыни? Сезгә перевод бар иде. Украинадан. Кул куеп алырга иде.

**Гыйльми:** Кызым, бабаң яңа гына яткан иде, арып кайткан. Үзең генә куеп бир инде.

**Почтальон:** Менә бу тәти абый куйсын, миңа ярамый бит.

**Фәрит:** Минем исемем бар, сеңелем – Фәрит. Бирегез /ала, кул куя/ Апа, хаты бар, укыйммы?

**Гыйльми:** Укы, улым, укы. Флерасыннандыр, онытмаганнар. Ай рәхмәт, балалар!

**Фәрит:** /укый/ “Кадерле әтиебез! 60 яшь тутыруың белән котлыйбыз, озын тигез гомер телибез. Әз булса да күчтәнәч җибәрәбез. Әнигә сәлам. Камиль, Флера.

**Почтальон:** /акча санап бирә/ Менә. Гыйльми апа, нәкъ 50 сум. Ярый. Сау булыгыз /китә. Гыйльми рәхмәт әйтеп озатып кала/.

**Фәрит:** /үзенә/ 50 сум! Шәһәрдән авылга 50 сум! /Гыйльмига/ Апа, улыгыздан булса кирәк?

**Гыйльми:** Юк, Фәрит, киявебез белән кызыбыздан. Әле генә бабагыз олы киявебез белән кызыбыздан пусилкә алып кайткан иде./Үзенә/ Ай, рәхмәт, балалар.

**Фәрит:** Кызларыгыз күптән читтәме соң, апа?

**Гыйльми:** Әйдә, улым. Алҗыгансыңдыр, чәй янында сөйләшербез, утыр. Олы кызыбыз Фәүзия 10 ел Тимертауда. Кызыбыз- инженер. Укып бетергәч, эшкә шунда җибәрделәр, Фәүзияне дә алып китте. Ә Флерасы институтта укыганда вәеннәйгә чыкты. Укып бетергәч, Украинага җибәрделәр. Кызыбыз – доктор, киявебез – командир. Харьковта алары.

**Фәрит:** Ярдәмнәре еш тияме соң?

**Гыйльми:** Ай саен җибәреп торалар, бик шөкер, Кеше улларыннан күрмәгәнне без кызларыбыздан күрәбез. Әйдә, улым, чәйләп җибәр, бабаң да уяныр. Зөлфия дә озакламас, кайтып җитәр. Сине соң нинди җилләр ташлады? Ни максат белән?

**Фәрит:** Мин Зөлфияне алып китәргә дип килдем. Аеры яшәп булмый бит.

**Гыйльми:** Ай-һай, улым, Зөлфия китәр микән? Эшен бик яратып эшли. Аннан... Аннан бер сынаганны мең сыный торган түгел ахры.

**Фәрит:** Ник алай дисең апа?

**Гыйльми:** Ник алай дип, бик җәберләгәнсең бит син аны. Хатын итеп алгач, ялчы итеп тотмаска иде.

**Фәрит:** Бер дә ялчы итеп тотмадым, эш кенә булмады, баланы яслегә урнаштырып җиткерә алмадым. Кеше хатыннары яши бит әле.

**Гыйльми:** Ничек яшәмәскә була. Без дә гомер иттек, кырык ел торып, бер беребезгә эх дип тә әйткәнебез юк. Әнисе ялгыз олы кеше икән, аны да тәрбияләмәгәнсез, ахры.

**Фәрит:** Хәзерге яшьләр арасында шулай, өйләнгәндә кызын да, анасын да ал дигән фикер бар – кызы белән тор, анасына бала карат, хезмәт иттер. Шундый хәл булмасын дидем.

**Гыйльми:** Кызын яраткач, анасын да яратырга кирәк иде.

**Фәрит:** Нәрсә, Гыйльми апа, Зөлфия барысын да сөйләдеме әллә?

**Гыйльми:** Юк, юк, ул андый күп сөйли торган бала түгел. Анасын чакыртып хат язган да: “Бездә сыярбызмы? – дип сорады, баласы барын әйтте. Хатын-кыз төпчөнә бит ул. Мин : “Ничек яшьли бала белән калдың?” – дип сорагач кына: “Шулай килеп чыкты инде, апа”,- диде.

**Фәрит:** Мин яшермим, Гыйльми апа, җәберләгән чагым да булгандыр, тормыш бит ул. Бер якта әни, икенчесендә – хатын. Әнине дә рәнҗетәсе килмәдә, ә ул көн туса , баерак Казан кызы бетмәс иде, каян таптың бу килмешәкне дип теңкәгә диде. Зөлфия: “Авылга китик, һич яшәргә мөмкинлек юк биредә”, - дип тилмертте. Күңелемә тынычлык табыйм дип салгаладым, ә салгач... Юкса Казанда да яшәргә була иде. Зөлфия бигрәк җиңел төяде. Мин эштә вакытта җыенып куйган да, язу калдырып, сызган.

**Гыйльми:** Сызарсың да, яшәрлегең калмагач, киткән инде. Алай, улым, ана белән хатын арасын төзәтерлек хәлең булмагач, анаң теләгәнгә өйләнергә иде.

Ярый, мин картны уятыйм әле, Көндезге аштан соң булса да ятып торыр. /китә/

**Фәрит:** /ялгыз/ Я, бу авыл өенең нәрсәсе бар инде? Бу тормышның ни кызыгы бар? Шушы авылның нәрсәсенә кызыга?
Ә хуҗалар... Күңелләре киңдер, шулай сизелә. Ай саен кызларыбыз ярдәм итеп торалар диләр, кая монда җиһаз?! Күрәсең, шушы тормыштан тәм табалар. Ярый, монда яхшы кыйланып торудан эш чыкмас. Ачыкларга да...

Тамак кырып Ясәви карт чыга

**Ясәви:** Ә-ә, кунак бар икән. Исән-сау килдеңме, егет?

**Фәрит:** Әйбәт, бабай, рәхмәт. Үзегез ни хәлләрдә яшисез?

**Ясәви:** Картларча шыгырдап... Бөтенләйгәме, әллә үтеп барышлый гынамы?

**Фәрит:** Өч көнгә сорап, Зөлфияне алырга дип килдем.

**Ясәви:** Ул сатып алынган товар түгел ич, алып китәргә. Үзе нәрсә әйтер. Әтнәкә, анысы үз эшегез. Безнең заманда: “Муж да жена – одна сатана» ,-ди иделәр. Әтнәкә, эшне көйгә салып китерә иде, китәр микәнни?

**Фәрит:** Ул килгәнче барган бит, туктамас. Хәзер эш бер кешедән тукталып тормый инде.

**Ясәви:** Тукталып тормый... Әтнәкә, Зөлфия килгәч, терлекчелектә чын тәртип урнаша башлаган иде. Әле иске короуникны мех...механик...механикалаштыру турында хыялланып йөри. Ферма эшчеләренең дә эшен җиңеләйтү өчен тырыша.

**Фәрит:** Гел эш турында гына уйлыймы? Әллә кичләрен дә шуның өстендә генә утыра?

**Ясәви:** Кичен мин каравылда булам, ләкин аны түгел, сыерлар каравыллыйм.

Утыралар.

**Фәрит:** Мине искә алгалыймы, бабай?

**Ясәви:** Ишеткәнем юк, эштә чакта эш турында сөйләшү, мин өйдә чакта, кайтып та керми, һаман эш дип йөри.
Син соң, улым, акылыңа яңарак килдеңме? Хатының бездә 3 ай, балаң аеры. Бу вакытка кадәр нишләп яттың?

**Фәрит:** Ир горурлыгы - үзе китте, үзе кайтыр әле, дидем. Килеп йөрмәскә дә уйлаган идем, вөждан мәҗбүр итте.

**Ясви:** Әтнәкә, улым, үзегез карасыз, миңа калса, һич җибәрмәс идем – эше эш инде, безгә дә бик әйбәт иптәш булган иде. Зөлфия бүлмәсенә кереп, ял итә тор, алҗыгансыңдыр.

**Фәрит:** Рәхмәт, бабай, юл кыенрак икән шул. Бераз ял итеп алу комачауламас иде. /Ясәви бүлмәне күрсәтә, үзе чыга/
Да, миңа да шушында килергәме? Юк, юк, кешегә гомер бер генә бирелә. Бирелә торган рәхәтнең барысын да татып калырга кирәк. Эш рәхәтен генә тоеп яшәү – кеше өчен бик аз әле ул. Эш шәһәрдә дә бар, ләкин чикләнгән. Ә бирдә? Көне юк, төне юк. Булмый, бусы белән һич килешеп булмый. Шулай да үзен күреп, тел төбен тартып карарга иде /утыра/.

/Ишектән атылып Зөлфия керә. Аякларында резин итекләр, өстендә халат/

**Зөлфия:** Фәрит! /ташлана. Фәрит Зөлфия өстендәге киемнәрне күреп туктап кала, кул бирә/

**Фәрит:** Исәнме, Зөлфия! Шулай да мин сине бу хәлдә күрермен дип уйламаган идем. Әллә киемнәр алыштырырга да мөмкинлегең юкмы?

**Зөлфия:** Фәрит!! Кешенең матурлыгы киемдә генәмени? Ярый, ярый, хәзер алмаштырам. Почтальон кыз ирегез килгән дигәч, эш киемнәремне салырга да онытканмын /бүлмәгә керә/

**Фәрит:** Менә сиңа мә! Терлек исе аңкып тора. Яшә инде син аның белән. Әни хаклы, бала дип барлы-юклы гомеремне тәмугта уздырып булмас. Алимент түләрмен, өстемнән бурычымны төшерермен, ләкин үзе Казанга барырга ризалашмаса, авылга килер хәлем юк.

**Зөлфия:** /чыга/ Түзмәс, мәхәббәте, баласы хакына килер , дип уйладым. И сагындым үзеңне, Фәрит! /бара, сыена/

**Фәрит:** /кочаклый/ Хәлең ничек?

**Зөлфия:** Әйбәт. Эшкә күнектем. Ялгызлык кына, икегезнең берегез булмавы гына борчый. Менә ничек сагынганмын!! Синең юл кешесе икәнеңне онытып җибәргәнмен... Әйдә, юын, чәй эчеп алырбыз.

**Фәрит:** Без апа белән эчкән идек, тамак туклыгын кире какмам.

**Зөлфия:** Өстәлне бирегә әзерлимме?

**Фәрит:** Кара-каршы утырып кына сөйләшеп ашардай урын булса, әйбәт булыр иде.

**Зөлфия:** Ярый, үземнең бүлмәдә генә ашарбыз. Мин хәзер йомырка гына кыздырып алып чыгам. Кыенсынмасаң , өстәл хәстәрен генә күрә тор/китә/

**Фәрит:** /ялгыз , өстәл әзерли/. Аның белән күңелле. Ләкин Әлфия дә әйбәт бит. Әни дә ярата. Зөлфия мине калырга кыстар инде, беләм, булмагач, булмый инде.

**Зөлфия:** /керә/ Менә тамак туклыгы, әйдә, утыр. Икмәк кенә кисә торсаң , мин самоварны алып керер идем.

/Чыга, чәшкәләр, аннан самовар күтәреп керә/

**Фәрит:** /икмәк кисә/ Зөлфия, Ильфакның хәле ничек? Килгәндә керә алмадым.

**Зөлфия:** Әйбәт. Әни соңгы хатында: “Хәзер күнегә төште, бик юксынмый”,- дип язган иде. Хәер, мин аларны чакырып яздым, хәзерләнә торырга куштым. Председатель машина белән барып алып кайтырсыз диде.

**Фәрит:** Өч кенә көнгә сорап килдем. Кайтыйк, Зөлфия, өчебез өч якта яшәмик! Сиңа эш тә белешеп куйдым. Элеккеге тормышның бөтен шартлары үзгәреп бетмәсә дә , үзең эшләгәч барысы да күзгә күренмәс.

**Зөлфия:** Әллә әни Ильфакны карамакчы булдымы? Аның пенсиягә чыгу вакыты да җиткәндер инде.

**Фәрит:** Анысын вәгъдә итми. Беләсең ич аны, пенсиягә чыксам, дөнья әйләнеп кайтам, үзегезне карап үстергән , миннән җитәр, ди. Ясли юк.

/Ишек кагалар/

**Наиль:** Мөмкинме?

**Зөлфия:** Керегез, Наиль, рәхим итегез.

**Наиль:** Бә... Кунак бар икән /кул биреп/, Наиль.

**Фәрит:** Исәнмесез, Фәрит.

**Наиль:** Бик әйбәт. Ә мин сезне туй мәҗлесенә чакырырга килдем. Менә чакыру кәгазе. Кич сәгать 6 га клубка рәхим итегез!

**Зөлфия:** Бик киң масштабта була түгелме соң бу, Наиль?

**Наиль:** Комсомол туе ясыйбыз дип аптыратып бетерделәр. Партком, комсомол комитеты, колхоз идарәсендә: “Туегызны гөрләтеп уздырабыз”, диләр.

**Зөлфия:** Бик әйбәт, урак бетеп килә. Туй ясау – эшне туктату түгел. Эше дә бара, ял да ителә. Рәхмәт, Наиль!

**Наиль:** Ярый, хушыгыз, кичекмәгез /китә/.

**Зөлфия:** Барырбыз бит, Фәрит? Авыл тормышын күреп китәрсең. Син бит аны практикада вакытта гына күрдең. Анысы да РТС та, район үзәгендә.

**Фәрит:** Мин бүген юлга чыгарбыз дигән идем. Китик, Зөлфия! Чистарак, эш көне дә дәүләт тарафыннан кертелгән сәгатьләр белән чикләнгән эш тә бар бит. Эшендә дә эшләрсең, ял итәргә дә мөмкинлек булыр.

**Зөлфия:** Ял... Өч ел ял иттем, җитәр. Соңгы елда бер театрга да алып бармадың. Хәтәр ял иде...

**Фәрит:** Миндә дә гаеп булгандыр. Үткәне үткән, киләчәге әйбәт булсын.

**Зөлфия:** Үзең белән килешер дә идем. Ләкин әнинең “килмешәк” дип мыскыллап-битәрләүләрен һич ишетәсем килми. Ачуың килмәсен, Фәрит, булдыра алмыйм. Әйдә, кил үзең! Биредә сиңа да эш бар, калган шартлары да туар.

**Фәрит:** Зөлфия, минем фикерем сиңа таныш, ләбаса. Дөрес, мин авыл специалисты, ләкин барлык авыл специалистлары да авылда эшләми ич. Теләсә нинди махинацияләргә керәләр, әмма шәһәрдә калалар.
Шулай булгач, миңа да шәһәрдә эшләргә мөмкин. Икенчедән, мин бит шәһәрдә туып-үскән кеше, анда миңа һәр таш кадерле.
Биредә, нәрсә бар? Эш, тик эш... Ә күңел ачардай, авырсаң дәвалардай, көн яңалыклары белән танышып торырдай нәрсә бар биредә? Культура шедеврларыннан нәрсә күрергә мөмкин?

**Зөлфия:** Әйе, авыл тормышына чирканып карау бар шул әле, Фәрит. Дөрес, шәһәрдә дә эшсезләр яшәми, ләкин ни өчендер яшьләр шәһәр ягын карыйлар. Синдә дә шул чир бар, Фәрит. Ә бит авыл тормышы шул кадәр куркыныч түгел. Кара син, биредә нинди киң күңелле хезмәт сөючән халык яши. Культура мәсьәләсе дә, син уйлаганча ук, начар түгел. Узган ел 550 урынлык яңа культура йорты төзелгән, эстрада оркестры алынган, кыллы оркестр бар. Яшьләр дә клубка теләп йөриләр. Син биредә культура ягыннан артта калганнар яши дип уйлама – биредә үзешчән сәнгать түгәрәгенә генә дә 50 дән артык кеше катнаша. Биредә культура шәһәрдән бер генә җире белән дә калышмый. Ай саен профессиональ артистлар килеп тора.

Әле шушы көннәрдә генә колхозның генераль планы тикшерелде. Быел агач йортлар урынына канализациясе, водопроводы, җылыту системасы булган икешәр катлы 24 әр квартирлы 4 йорт салына башлаячак. Киләсе елга йортларга газ кертеләчәк. Ә мунчасы, кер юу урыны?
Хәер, син моны аңламассың шул, сиңа шәһәр кадерле.

**Фәрит:** Сүз көрәштермик, Зөлфия, киләчәкне күздә тотыйк, балабыз язмышын онытмыйк. Ул авылда нәрсә күреп үсәр? Аны нәрсә көтәр?

**Зөлфия:** Авылда үскән кешеләр арасыннан да бөек кешеләр чыккан. Теләге булган кешегә бездә бер төрле киртә дә юк. Син моны яхшы аңлыйсың. Ә балабыз бәхетсез булмас.

**Фәрит:** Аеры тору – фикер каршылыкларыбызны киметү түгел, тирәнәйтә генә төшергән икән. Мин шуны аңладым.

**Зөлфия:** Минем бер генә сорау бар – без кадерлеме сиңа, юкмы? Әллә вөҗдан бурычыңны гына үтәргә килдеңме?

**Фәрит:** Әйе. Вөҗдан бурычын үтәргә килдем. Кайтасың икән , рәхим ит. Кайтмасаң, мин китәм, башка көтмә!! Ялынып йөри алмыйм. Балага алимент түләрмен.

**Зөлфия:** Эх, Фәрит, Фәрит... Безнең дөньяга карашларыбызда нинди аерма!!

**Фәрит:** Мәсьәлә ачык кебек. Уртак тел таба алмабыз булса кирәк. Мин юлга чыгармын, ахры.

**Зөлфия:** Хәерле юл. Син бит : “Миндә гаеп калмады, чакырдым, вөҗдан бурычымны үтәдем, эш үзендә калды”,- дип әйтү өчен генә килгәнсең. Хуш!

**Фәрит:** Хуш, матур яшә... /китә/

**Зөлфия:** Китте бит... /башын тотып кроватька ава, үксеп елый/

ПӘРДӘ

## III - ПӘРДӘ
## I-КҮРЕНЕШ

Колхоз идарәсе. Уртада 10-20 кешелек өстәл, урындыклар. Зур өстәлгә перпендикуляр кыскарак өстәл. Киңәшмә бара. Биредә Илһам, Равиль, Зөлфия, Люция

**Равиль:** Аңлыйм, иптәшләр, иске фермада да кул хезмәте сорый торган эшләрне җиңеләйтү кирәк, ләкин быелга булмый: урак бетеп җитмәде, яңа коровникның эше төгәлләнмәгән, мәктәп зданиесен 1 сентябрьгә өлгертергә кирәк. Практически эшли алмыйбыз быел. Ничәгә ярылыйм иде?

**Илһам:** Уйлап карыйк әле, Равиль, яшьләр игътибарга лаеклы тәкъдим белән килгәннәр. Минемчә, колак салырга кирәк.

**Равиль:** Эш тәкъдим белән генә эшләнми. Нинди яхшы булса да ул тәкъдим булып кала.

**Люция:** Равиль абый, беләбез, эшегез күп, масштабы зур, ләкин безнең тәкъдимгә кушылырсыз дип уйлыйбыз.

**Зөлфия:** Фермага реконструкция кирәкми. Расход та күп чыкмаячак. Терлекчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү – безнең бурыч ич. Нигә анда эшкә бармыйлар, барсалар да энтузиастлардан кала качу ягын карыйлар? Төп сәбәп – авыр эш. Бөтен эш кулдан үтә. Көн саен һәр сыерга 60 кг азык бирелә, күпме тирес чыга. Кул эше бит бу.

**Равиль:** Беләм, беләм, авыр ләкин хәзергә мөмкинлегебез юк, факт. Ладно, тәкъдимегезне әйтеп карагыз.

**Илһам:** Зинһар, тавышыңны күтәрмә. Үзләре өчен түгел, халык өчен йөриләр бит иптәшләр.

**Равиль:** Икмәк сату графигы өзелде. Төзүчеләрнең түбә материаллары беткән. Кызарсың да. /акрынрак/. Тыңлыйм.

**Зөлфия:** /бер табак кәгазь сүтеп өстәлгә җәя, барысы да иеләләр/. Менә карагыз, бөтен кирәк материалларның якынча исәбе, механикалаштыру планы. Без аны Наиль, Фәнис белән эшләгән идек. Бәлки Наиль ышандырырлык итеп сөйләр иде, имтиханга хәзрләнүеннән бүлмик дидек.

**Илһам:** /якынрак килеп/ Сөйлә, сөйлә, Зөлфия!

**Зөлфия:** Урта коридорның идәненә нәзек рельс белән юл салабыз. Моның өчен 300 метр рельс җитә. Бу юлдан корморaздатчик йөри. Ике вагонетка кирәк. Аның берсен печән, салам кертү өчен фургон итеп эшләргә, ә икенчесен парландырылган азыклар, силос бирү өчен хәзерләргә кирәк.

**Фәнис:** Мин слесарьлар, тимерчеләр белән сөйләшкән идем. Алар, рельс белән вагонетка тәгәрмәчләре булса, калганын үзебез эшлибез диләр.

**Равиль:** Да... /башын тота/.

**Илһам:** Я-я, тагын нәрсәләр?

**Зөлфия:** Тирес чыгару өчен тагын ике вагонетка кирәк. Башта без кыр-кырга да тимер юл салырга планлаштырган идек. Болай булса, аларыннан азык, ә уртадагысыннан тирес чыгарырлык итәрбез дип уйлаган идек.

**Равиль:** Уттай эш өстендә кеше каян алыйк, рельсларын, тәгәрмәчләрен каян табыйк? Минем уйлавымча, тамборларга да үзгәреш кертергә туры килә. Сез уйлаганча җиңел генә була торган эш түгел бу, иптәшләр.

**Люция:** Равиль абый, сез рельс белән тәгәрмәчләрен таба алсагыз, калганын бер тиен дә сорамыйча, үзебез эшлибез. Безнең тәкъдим шул – материал булса, комсомол өмәсе ясыйбыз. Җыелышта мин бу мәсъәләне күтәрдем, комсомоллар ике куллап риза.

**Равиль:** Комсомолларның төп эшләре дә бар, алар кырда.

**Люция:** Производствода эшләүчеләре дә ризалар.

**Илһам:** Димәк, безнең бурыч – материал табу. Минемчә, тизәк чыгару өчен җирдәге юлга параллель итеп, асылмалы юл уздыру файдалырак булыр. Коридор түшәмен бераз күтәрә төшсәк бу җиңел хәл ителәчәк. Ә җир өстендәге юлга химзводның сүтелгән юлыннан алынган рельслардан файдаланырга мөмкин. Сөйләшү тәмамлану белән мин заводка китәм, алып та кайтырбыз!

**Фәнис:** Әйбәт тә булыр иде. Кормозапарниктан да юл чыкса, терлекчеләрнең эше 20-30 % җиңеләячәк. Илһам абый, борылмалы рельслар да булмасмы?

**Равиль:** Чынладыгыз, ахры, иптәшләр, миңа да читтә калырга туры килми. Җиңдегез, факт. Иртәгә районга баргач, асылмалы юлга кирәк әйберләрне сельхозтехникага кереп белешермен. Хотя, хәзер үк булыр /телефон трубкасын ала/

Миңа 1-08 не бирегез әле. Кем бу? Рафаэль Кашапович, исәнмесез! Булатов әле бу. Сездә навесной рельслар бармы? Фермага кирәк иде, 300-400 метр. 150 метр гына? Әзрәк икән шул. Кайтасы юкмы? “Күмәк көч” тә бар дисезме? Яхшы. Безгә булганын оформить итәрсез бит? Яңа коровникка УДМ -8 кайтмадымы? Бөгелмә базасында бар? Яхшы, безгә оформить итегез, шушы арада барып алырбыз. Ярый, рәхмәт. Хәзергә /трубканы куя/.
Болай булгач, җигелергә туры килә. Зөлфия, Фәнис, инженер-механик, бригадир белән бөтен эш операцияләрен тагын бер кат уйлашыгыз әле, кирәк материалларның исемлеген хәзерләгез. Иртәгә кичкә керерсез.

**Илһам:** Өмәне кайчанга планлаштырасыз, Люция?

**Люция:** Урып-җыюны бетергәч тә, бәрәңге ала башлаганчы. Якынча 10 көннән.

**Равиль:** Материалны туплый торабыз. Хәзерләнегез!

**Зөлфия:** Әйбәт булыр. Яңа ферманы маллар кергәнче өлгертү турында да истән чыгармыйк әле, иптәшләр.

**Фәнис:** Түбә материалына нишлибез инде, Равиль абый?

**Равиль:** Шифер бүген кайтыр, алырлар. Ярый, иптәшләр, озакладык. Иртәгә УДМ-8 гә наряд алып кайтырмын. Дәүләткә икмәк сату йөкләмәсен үтәү белән алып кайтырга кирәк. 4-5 көннән мөмкин булыр.

**Илһам:** Зөлфия, бәлки семьяңны юл уңаеннан алып кайтырсың?

**Зөлфия:** Әйбәт булыр иде. Иртәгә үк вызов белән сөйләшәм, хәзерләнә торырлар.

**Фәнис:** Үзем барам, Равиль абый. Кирәк материалларны сайлап аласы булыр. Зөлфиянең әнисен дә кереп алырмын.

**Равиль:** Әйбәт булыр.

**Люция:** Ә Наиль белән Нурияне озату кичәсен кайчанрак оештырырбыз, Илһам абый?

**Илһам:** Туйларын гөрләтеп үткәрү генә түгел, менә дигән итеп озатырга кирәк, хәзерләнә торыгыз, Люция.

**Фәнис:** Икесе дә колхоз степендиаты булып китәме?

**Равиль:** Идарә шундый карар чыгарды, тырышып укысыннар гына.

**Фәнис:** Бөтен кеше укыганда миңа да болай йөрү килешми. Киләсе елга заочно булса да керәм.

**Илһам:** Бик әйбәт булыр, Фәнис, заманача яшәргә кирәк.

**Люция:** Ярый, мин китим әле. Сау булыгыз!

Икенче ишекне кагалар. Фатыйма керә, кулында чемодан, өстендә заманча плащ.

**Фатыйма:** Ялдагы кешене каршы алырга машина да җибәрмиләр... Исән-сау гына тордыгызмы?

**Илһам:** Җимертеп торабыз, Фатыйма апа. Хәбәр дә бирмисең. Исән-сау кайттыңмы?

**Фатыйма:** Шөкер, бик шөкер. Кайтышлый ук , мәйтәм, рәхмәт әйтеп чыгыйм әле.

**Фәнис:** Күңелең булырлык ял иттеңме, Фатыйма апа?

**Фатыйма:** Тол хатынның күңелен булдырыр өчен күп кирәкми, энем, бик булды... /кинаяле итеп/. Әле Фатыйма апагыз әздән калды...

**Зөлфия:** Алай дисең әле син, Фатыйма апа...

**Фатыйма:** Шулай, Зөлфиякәй, сиңа серем бар, үзеңә генә сөйләрмен әле.

**Равиль:** Ярый, иптәшләр, мин башка бригадаларга чыгып кайтыйм әле, син нишлисең, Илһам?

**Илһам:** Сөйләшкәнчә заводка барам. Комбайнерларның эш нәтиҗәсен белешеп кайтырсың бит?

**Равиль:** Ярый. Мин 2-3 сәгатьтән кайтырмын /китә/

**Илһам:** Фәнис, син минем белән бармыйсыңмы?

**Фәнис:** Лагерьга төшәргә вакыт җитте, бара алмам, Илһам абый. Сельхозтехникага керсәгез ПДУ-1 гә вакуум-насос булмасмы?

**Илһам:** Ярар. Хәзергә, иптәшләр.

**Фәнис:** Зөлфия, терлекләрне үлчәү нәтиҗәләрен генә җыеп куймассыңмы? Соң булса да, кайтышлый сугылырмын /китә/

**Зөлфия:** Фатыйма апа, син өеңә дә кайтмагансың, әйдә безгә барыйк. Чәй эчәрбез, бераз сөйләшеп утырырбыз.

**Фатыйма:** Рәхмәт, канатым, өйгә кайтмыйча кешегә кереп йөрү әйбәт түгел. И-и, Зөлфия, кем белән күрешкәнемне беләсеңме?

**Зөлфия:** Кем белән икән, бер дә әйтә алмыйм бит.

**Фатыйма:** Кайнанаң белән /Зөлфиянең игътибары туплана/

**Зөлфия:** Булмас... Я-я?

**Фатыйма:** И тетте үзеңне, белсәң иде, пешмәгән, килмешәк, әрәмтамак...

**Зөлфия:** /үзенә/. Урамга чыгып кычкырасы калган иде, ансын да эшләгән икән. /Фатыймага/ Аны кайда күрдең? Син Кавказда, ул Казанда ич?

**Фатыйма:** Самолет белән Казанга килеп төштек. Томан булгач, самолетлар очмый торды. Минем кырга килеп утырды, сөйләшә киттек. Үземнең кайдан икәнемне, нишләп йөрүемне әйткәч, сөйләшеп китте: "Минем килмешәк киленем дә шул якта. Рөхсәтсез-нисез китеп барды. Үзен кызык иттек. Улымны ике генә көн элек менә дигән Казан кызына өйләндердем. Рәхәтләнеп торсыннар әле, бер-ике атнага олы улыма барып кайтырга чыктым. Гомерем эшләп үтте, сәламәт чакта дөнья күреп кайтам әле",- ди. Утлар чәчә. Хәтәр хатыннар бар икән...
Мин: "Килмешәк киленең законлы никахта тора торгандыр бит?" – дигәч, "Анысы баш бәласе түгел, законлы никахны закон көченнән чыгарабыз" дип кенә җавап бирде.

**Зөлфия:** Әни булмагандыр ул. Шундый язмышлы кеше мин генә түгелдер...

**Фатыйма:** Галәмдә охшаш язмышлар булса да, бу синең биемең иде. Ул синең исемеңне дә, зоотехник икәнеңне дә, улыңны әниеңә калдырып, эшкә китүеңне дә, улы Фәритнең синең яныңа килеп, күз буяу өчен генә "кайтыйк, тормышны яңартыйк" дип әйтүләрен бәйнә-бәйнә сөйләде. Мин: "Бездә дә Зөлфия исемле зоотехник кыз бар, ләкин ул яшь әле", - дигәч, "Аның кызлыгы маңгаена язылмаган",- диде.

**Зөлфия:** /салкынаеп/ Килененең исемен әйтмәдеме?

**Фатыйма:** Әлфия диде ахры. Әллә төзүчеләр институтын бетердем ди, мин аны аңлап бетермәдем. Ачуланма, Зөлфия, бәлки әйтергә кирәк тә булмагандыр. Ярый, мин кайтыйм инде. /Китә/.

**Зөлфия:** Алай... Брысы да ялган булган... Сөям, имеш... Хамелеон. Тасма тел. Шул кирәк мин җүләргә. Бәлки мин анда вакытта ук йөргәндер. Мине китәргә мәҗбүр итәр өчен икәүләп кәмит куйганнардыр. Ярый, күңеленә охшаганы белән торсын. Ә бала?.. Үземнең ятим үсүем генә җитмәгән иде... Дөрес, минем ятимлек тормышның әче язмышы. Әти-мәрхүмне фронт яралары алып китте.
Ильфак - әтиле ятим. Улым да, минем кебек, әтиләре җитәкләп баручы балаларны күргән саен, миндәргә капланып: "Минем әтием кая, әни?"- дип елармы... Әтиле ятим... /елый/.

ПӘРДӘ

3 ПӘРДӘ

II- КҮРЕНЕШ

/Шул ук күренеш. Вакыйга 8-10 көн соңрак бара/.

Имай керә.

**Имай:** Беркем дә юк икән. Өмәдәдер инде... Я агай, ниләр генә күрми бу газиз баш. Семьям да юк, җитмәсә иптәшләр судының карары... Эш 10 тәңкә штраф түләү белән генә бетми әле. Вөҗданыма бик нык кагылдылар. Ничек кенә ышанычларын акларга инде? Болай шәп түгел бит...

Нәрсәдән генә башланды соң бу? Нүҗәли үзем дә сизмәдем? Сиздем, әмма каршы тора алмадым. Баштарак бәйрәмнәрдә, аннан өй җиткергәндә ... Ахмак... Эшчеләргә дип үзем кудым, бер ай буе бер генә буш көн дә калмады бит. Өйне эшләп бетергәч, эш беткән шатлыктан... Әйе... Тора-бара ашар алдыннан даруга, имеш. Шулай агулый икән бу каһәр суккан яшел елан. Тукта әле, нигә дип кердем соң мин бирегә? Ә-ә, вәгъдә бирергә, больницага китүемне әйтергә...

Әллә соң барысы чукынып китмиме дип, тагын берәр чәки йөртергәме? Пажалый, луще булыр /ишеккә таба бара/. Юк, ярамый. Бүген үземне җиңә алсам, кеше рәтенә керергә мөмкинлек алам, җиңә алмасам, бетте түгелме соң? Айдан артык семьясыз. Аның өстенә бу суд дигәне... Ай, чукынып киткере дөнья... Кыен булса булыр, болай булмый. Имаметдин! Җитәкчеләрнең кайтканын көт! /Утыра/. Ай, бәхетсез баш.../башын тота/. Кем гаепле? Үзем гаепле. Иртәгә үк больницага. Урыныма кеше куйсыннар, мин китәм.

/Яшьләр “Төзүче” җырын җырлап үтәләр. Имай уйлана/.

Менә бит. Уттай эш өстендә, аракыдан дәваланам дип йөр, имеш... Кеше эштән кайта, ә син суга төшкән тавык кебек, бирәдә утыр. Ай, Имай, Имай... /почмактагы урындыкка утыра/.

Равиль, Илһам керәләр.

**Илһам:** Теләк булса, тауны тишәсең, дигәндәй, уйламаганда менә дигән файдалы эш эшләп куйдык бит.

**Равиль:** Катнашучылар күп иде. Кара син, бөтен терлекчеләр чыкканнар, күрәмсең, күптән көткәннәр. 80 кеше санадым. Зөлфия – молодчина, факт. /Имайны күреп/ Бәлеш, нишләп утырасың, Имай абый? /Имай тора/. Бөтен кеше эштә, ә син идарә саклыйсың. Әллә иптәшләр суды карарына жалоба белән килдеңме? /Өстәл артына утыра, наряд яза/.

**Имай:** Юк, Равиль, мин үз эшем белән килдем. Ә өмәгә чыкмавымның сәбәбе – кеше күзенә күренергә оялдым. Кичәге суд карарын әллә ничә урынга элгәннәр. Килүемнең максаты – урыныма кеше куеп торыгыз, иртәгә больницага китәм.

**Илһам:** Имай абзый, больницада алган дәваны эчү белән юкка чыгармассыңмы? Әллә бармыйча, үзең генә дәваланасыңмы?

**Имай:** Ничек?

**Илһам:** Син бүген аек. Димәк, эчмичә дә тора аласың? Әгәр 10, 20, 50, 60 көн эчми торсаң, ташларга мөмкин бит.

**Имай:** Әй, энем, энем, аңлагыз инде. Минем вәгъдәләремә Нәҗия апагыз кул гына селти. Лечение алып кайтсам, анда да авылдашларда да ышаныч туар иде, димен. Миңа да рәхәт түгел бит, кемгә карама – нәфрәт.

**Равиль:** /эшеннән аерылып/Ярый, Имай абзый, әгәр алай уйласаң, без каршы түгел. Бар, дәваланып кайт... Бәлки кайтуыңа Нәҗия апа, балаларың өеңдә утырырлар. Берьюлы ике шатлык булыр.

**Имай:** Эх, егетләр, бер атна гына дәваланып чыксам да, җитәр иде – кулыма да алмас иде чукынганны. Ярый, егетләр, вәгъдә – минем хакта бу мәсьәләдә сүз булмас, ышаныгыз! /китә/.

**Илһам:** Вөҗданыма суккан абзыйның. Ник аңа барырга тәкъдим иттең, эчү гадәтен көрәш юлы белән бетерер иде. Минемчә, аның 6-10 көн больницада ятып чыгуы психологик барьерны җиңү өчен кирәк. Ишетмәдеңме, нәрсә сөйли? Ул очракта да көрәш кирәк булыр әле аңа. Нәҗия апа белән сөйләшеп кую комачауламас.

**Илһам:** Әйе, үзем күреп сөйләшермен. Семья өчен көрәш, кеше тәрбияләү дә безнең бурыч, вөҗдан бурычы. Ярый, иртәгә өчен нәрсәләр планлаштырдың?

**Равиль:** Дәүләткә сатасы икмәкнең соңгы тонналарын озатабыз. Яңа фермага УДМ-8 не алып кайтыр инде, аны урнаштырырга кирәк.

**Илһам:** Кукуруз уздыргычны, бәрәңге алдыргычны тагын бер мәртәбә тикшереп чыгарга, колхозчыларга сатыласы ашлыкны сатуны да планлаштырырга кирәк, коры чакта хәл ителсен.

**Равиль:** Ведомостьлар хәзер булса, иртәгә үк башларга мөмкин. Илһам, Ясәви бабайны яшьләргә үрнәк күрсәтеп, киңәшләр биреп йөрүен, чын күңеле белән эшләвен күргәч кенә, аның бу айда пенсия алачагы искә төште. Өмәдән кайткач, сугылырсың әле дигән идем. Аңа складтан электр самовары алдырдым, теге якта. Әллә бүген шушы айда пенсия алачагын белдереп, рәхмәт әйтеп җибәрикме?

**Илһам:** Пенсионерларны тантаналы җыелышта олылап озату яхшырак булыр, миемчә. /кәгазьләр актара/.

**Равиль:** Ул безнең персональ пенсионер бит, әле ничек кенә озатырбыз. Җаның не җалкы андый тырышларга, факт. Ә монысы исенә төшерү генә – күктән төште бу акча димәсен. Эшләп йөрмәсә дә ярый бит аңа.

/Ишек шакыйлар, Зөлфия керә/.

**Зөлфия:** Мөмкиндер, икегезгә дә рәхмәт, бик күп эш эшләнде бүген.

**Илһам:** Үзеңә рәхмәт, тынгысызлар максатка тизрәк ирешәләр, молодчина.

**Зөлфия:** Иртәгә дәүләткә дуңгызлар илтәсе көн иде. Наряд булдымы, Равиль абый?

**Равиль:** Ике машина барачак. Өчәр рейс ясарлар. Үзеңә дә барырга туры килер инде, Зөлфия.

**Зөлфия:** Ярый, мин документларны әзерли торыйм /үз өстәле артына утыра, кәгазьләр ала, счетлый/.

/Тамак кырып Ясәви керә/

**Ясәви:** Юкка чакырмас, берәр важный эш бардыр, гәүдә оеганчы барып кайтыйм дип килдем.

**Равиль:** Әйдүк, әйдүк, Ясәви абзый! Алай важный эш юк, рәхмәт әйтергә чакырдык.

**Ясәви:** Рәхмәтне урынында әйтергә кирәк. Беләсегез килсә, мин рәхмәт өчен эшләмим, гражданлык, вөждан бурычын үтәргә телим. Әтнәкә, юкка гына килгәнмен...

**Илһам:** Ясәви абзый, сиңа ничә яшь инде?

**Ясәви:** 60 сукты балалар. Әтнәкә, эш яшьтә түгел, йөрәктә, ә ул 18 яшьлек кенә әле минем.

**Рәвиль:** Сиңа лаеклы ялга вакыт, тырыштың, рәхмәт. Бу айдан колхозның персональ пенсиясен ала башларсың, Ясәви абзый.

**Илһам:** /чыгып самоварны алып керә/. Сине, Ясәви абзый, официаль формада озатканчы, исеңә төшерик, истәлек бүләге биреп җибәрик дип чакырган идек.

Менә, Гыйльми апа белән яндырып чәй эчәрсез, бу айдан башлап. Электр энергиясе дә бушлай булыр.

**Зөлфия:** Без өчәү әле...

**Рәвиль:** Өчәүләп эчсәгез дә гаеп булмас. Ясәви абзый, тырыш хезмәтең, саф намусың өчен рәхмәт. Тынычлап ял итегез! Ә көзен эшләр беткәч, тагын бер сөйләшербез әле, күп калмады.

**Ясәви:** Тәнемдә көч барында, йөрәгем типкәндә эшлим әле, балалар. Әтнәкә, ихтирамыгыз өчен рәхмәт. Гыйльми апагызны сөендерим әле. Кызым, чәйгә сине көтәрбез.

**Зөлфия:** Ярый, бабай, мин ярты сәгатьтән кайтып җитәрмен.

**Ясәви:** Ярый, ярый, барыгызга да рәхмәт. Башка йомышларыгыз булмаса, мин китим инде, балалар. Хушыгыз, ат башы кадәр рәхмәт!

**Равиль:** Исән-сау яшәгез, үзеңә рәхмәт. Онытып бетермә, Ясәви абзый, килгәлә!

**Ясәви:** Колхоздан башка миңа тормыш юк, әбизәтильнә киләм. Хушыгыз! /үзенә/Әй, заман... Ялга акча биреп чыгаралар бит ә... Әтнәкә, бу совет хөкүмәтенә рәхмәт яусын/китә/.

**Зөлфия:** Наил белән Нурияне әйтәм, иртәгә китәбез, диләр. Ә бүген өмәдә икәүләп йөриләр. Фәүзия апаны күрсәгез! Гел гаҗәп. "Бу кадәр шатлыклы көннәрне күрермен димәгән идем, килде. Барсыннар, укысыннар, 4-5 елга түзмәс кеше булмас, сынатмам, йөзләренә кызыллык китермәм,- ди. Ә-ә, бүген аларны озату кичәсе бит әле. Илһам абый, сез барасызмы?

**Илһам:** Обязательно!

/Ишек кагалар, Наил белән Нурия керәләр/.

**Наил:** Равиль абый, Илһам абый, Зөлфия! Барыгызга да рәхмәт, ышаначыгызны акларга тырышырбыз. Ә 4-5 елдан кайтып та җитәрбез. Рәхмәт!

**Равиль:** Бүген озату кичәсе икәнен онытмадыгызмы? Җылы сүзләрне анда әйтербез. Ә иртәгә станциягә "Волга" илтеп куяр. Молодцы, киләчәктә дә шулай булыгыз!

**Нурия:** Зөлфия апа, минем сыерларны обидага бирмәгез, яме!

**Зөлфия:** Юк, агрегатны Нургали эшләтәчәк, ә синең сыерларны Фатыйма апа белән Гөлшатка бүләбез.

**Илһам:** Ике сәгатътән кичәгә рәхим итегез!

/Машина тавышы, Фәнис атылып керә. Зөлфия тора, аңа таба бара/

**Фәнис:** Булды, Равиль абый… кайтты. Ферма кырына бушаттык, разборный, җыясы булыр инде. Зөлфия, әби белән малайны алып кайттым!

**Зөлфия:** Рәхмәт, Фәнис! Мин китим әле! /китә башлый/.

**Фәнис:** Зөлфия, әз генә сабыр ит! Эх, Наил, китәсең инде, менә дигән универсал саудыргыч алып кайттым. Ярый, укыгыз, пока без эшли торырбыз.

**Нурия:** Без кайтып хәзерләнә торыйк, Сәгатъ 8гә клубка!

**Наил:** Тагын бер кат рәхмәт. Персональ рәхмәт әйтергә кергән идек, бурычны үтәдек. Әйдә, Нурия, очрашканчы, иптәшләр!

**Равиль:** Фәнис. ПДУ га запчастьлар булдымы?

**Фәнис:** Урын калмады, шулай да кирәкләре кайтты.

**Илһам:** Син юкта без дә тик ятмадык. Планлаштырылган эшләрне арттырып үтәдек, тамборларны да үзгәрттек, юл да эшләнде.

**Фәнис:** Яхшы булган, мин генә катнаша алмадым, хәер, уйнап йөрмәдем инде.

**Равиль:** Иртәгә өчен наряд биреп чыгыйм инде. Илһам, синең бригадирларга әйтәсе сүзең бармы? Чыгыйк, без хәзер./китәләр/.

**Фәнис:** /Зөлфиягә омтыла, кулын тота/. Зөлфия, мин әби белән улымны үземә алып кайттым. Әйдә, кайтыйк!

**Зөлфия:** Фәнис, мин бит ир хатыны...

**Фәнис:** Кадерлем, синең намусыңны аяк астына салып таптаган кешене ничек ир дип атыйсың? Синең тырнагыңа да тормый ич ул шарлатан. Өйләнде, мин хатынлы ир димәде, эгоист, ә син һаман , мин ир хатыны, дисең. Аның белән булга никахны мәгънәсез буларак, үзебез таркатабыз, ә безнекен законлаштырабыз.

**Зөлфия:** Фәнис, бу көнгәчә күңелемдә булганны әйтмәдем, яшердем. Тыңласаң, бүген әйтәм. Хөрмәт итәм мин сине. Синең тәвәккәллегең, тырышлыгың, олы күңеллелегең алдында баш иям. Синең бу сыйфатларың авыр вакытларымда көч бирделәр, үрнәк булдылар. Ике-өч ай эчендә минем идеалыма әверелдең син. Ләкин безне ике якка аеручы бала бар. Беләм, син: “ Миңа үз баламнан да кадерлерәк ул”- диярсең. Ләкин аңла, синең каның түгел ул. Кайчан да булса синең ир горурлыгың уяныр, дөньяда балалы хатыннан башка ефәктәй кызлар беткән идеме миңа диярсең. Мин моңа риза түгел. Язмыш миңа тол булып җафаланырга кушкан икән, икенче кешенең дә газаплануын теләмим мин. Чынлап әйтәм, Фәнис, кадерлем.

**Фәнис:** /Зөлфияне кочаклап ала/. Кадерлем, минем башыма да килмәгән нәрсәләр турында сөйлисең син. Миңа син шулай кадерлерәк: каршыма әллә нинди матурлык патшаларын китереп куй, берсенә дә карый алмыйм мин аларның. Син минем өчен матурлардан матуррак. Ә бала өчен борчылма! Ул миңа ата буларак, күп бурычлар йөкли. Ләкин, ышанып әйтәм, теләсә кем алдында, һәркайда мин аңа ата булырмын. Аның үгилеген сизмәссең, чөнки ул – синеке, ә син- минеке, димәк, ул да минеке. Тудырган кеше ата-ана булмый, үстергән – ата-ана була, син моны беләсең. Вөҗданым саф. Аңа соңгы сулышыма кадәр тап төшермәм. Вөҗдан бурычы – минем өчен изге, кадерлем!

/Илһам, Равиль керәләр/

Илһам абый, Равиль абый сезнең алдыгызда әйтәм – мин Зөлфиянең кулын гомерлеккә сорыйм. Әйтегез, бер- берегезгә лаеклымы без?

**Илһам:** Лаеклар сез, Зөлфия, Фәнис! Матур киләчәккә сез аеры бара алмассыз, минемчә. Тәбрик итәбез!

**Равиль:** Ак бәхетләр сезгә, алтын кешеләр!

**Зөлфия:** Теләкләрегез өчен рәхмәт, абыйлар! Ә сез, кешеләр, безнең бәхетле булуыгызга ышанасызмы? Мондый язмышлар очрый бит дөньяда... Киттек, Фәнис!!

Р. Башаров